Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ 3/ 2021

Колак сыман чигү техникасы («тасмалардан элмәкле аппликация» / «тырнак алмалау») – чәчәк таҗы кебек бөтерелгән тукыма кисәкләреннән рельефлы чәчәк композицияләре булдыруны күздә тота торган аппликациянең бер төре. Әлеге техника Казан татар хатын-кызларының баш киемнәрен бизәр өчен кулланылган

С праздником,
Татарстан!
Бәйрәм белән,
Татарстан!

Гармун
сайлый егет

Рөстәм Сүлти сүзләре,
Инсаф Хәбибуллин көе

Бармаклары белән гүя,
Гармун телләрен саный.
Берсен ала, берсен куя,
Бер егет гармун сайлый.

Кушымта:
Гармун сайрый сандугачтай,
Гармун сайрый да сайрый.
Көйгә көйне ялгый-ялгый,
Бер егет гармун сайлый.

Уйнамый түзеп буламы,
– Кулда гармун булганда?!
Тын гына торып кара син
Жаның моңга тулганда.

Кушымта.

Кызлар күңелен җилкетер
Гармуннар бармы монда?
Тукта-тукта, нинди көй бу?
Йөрәкне урый моңга!

Кушымта.

Бу елның 30 августында – Татарстан Республикасы көнендә «Уйнагыз, гармуннар!» халык иҗаты бәйрәме узды. Бирегә Татарстан һәм Россия төбәкләреннән 1000нән артык гармунчы җыелды. Г. Камал театры алдындагы сәхнәдә башланып киткән бәйрәмдә җыр һәм бию фольклор ансамбльләре, татар эстрадасы артистлары чыгыш ясады. Бәйрәм тантанада катнашучылар һәм гармунчылар парады белән дәвам итте. Аны Татарстан Республикасының Мәдәният министры Ирада Әюпова һәм Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев җитәкләде.

Түгәрәк уен

№ 3 2021

Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,
моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.
Г. Тукай

16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгы каршындагы
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590.
Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛. Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 15.09.2021
Чыгу көне: 22.09.2021
Заказ: 016786
Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:
420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Кучереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

Тышлыкта: Калфаклар. Казан губерниясе.
XIX гасырның беренче яртысы. Бәрхет, тасма, бисер, канитель, «колакландырып» бөтерелгән аппликация, бисер белән чигү.
Татарстан Республикасының Милли музееннан

© «Түгәрәк уен», 2021

ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

4 **Ага Базар – иң зур базар**
6 **Казанны гөрләткән I Этно-fashion фестиваль**
10 **Татарстанда ел һөнәрчеләрен билгеләделәр**
12 **Кайбычта «Кичке уен» + «Uen Fest»**
14 **«Түгәрәк уен» яши – рәхәтләнеп карадык»**

2021 – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

16 Р. Шәрипова
«Чатыр тау – туган якның кыйбласы, шәмаиле!»

ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ

20 Л. Саттарова
Коръән савытлары

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ

26 З. Бруськo
«Әлли-бәлли, бәлли-бәү...»
30 М. Гайниева
«Беренче көлтә» бәйрәме
34 Р. Әхәтова
Ашыт җыены

ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС...

37 Е. Шемелева
Смәел осталарының тылсымлы талчыбыгы
40 Ф. Мәрданова
Колак сыман чигү техникасы

ӘДӘБИ МИРАС

44 Л. Мөхәммәтҗанова
Сөмбел чәчле татар Ләйләсе

КУНАКХАНӘ

50 Ф. Лотфуллина
Һәр заманның үз көе

БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ

54 **Халык зирәклеге әкиятләрдә чагыла**

55 **Васыять**

БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...

56 Р. Шәйдуллина
«Кәккүк чәе» бәйрәме
(Мәктәпкә хәзерлек төркеме өчен)

59 **Сары агачлар** *(Җыр)*

ӨЙ КҮРКЕ – АШ

60 **Эчәк бөккәне**

ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ

64 **Шахворд**

АГА БАЗАР – ИҢ ЗУР БАЗАР

«Ага-базар бөтен Итил, Чулман буенда, Хазар йортның ханбалыгы Итил-торадагы базарлардан кала, иң зур базар санала иде. Бөек Итил, язгы боздан әрчелеп, яңадан боз белән капланганга тикле монда җир йөзенең барлык якларыннан, каекларга утырып, төрле ил сатучылары килә иде. Базар монда язын-җәен-көзен генә түгел, кыш көннәрендә дә тукталып тормый иде. Болгар йортының бу атаклы базарында күңелең ни тели – шуны сатарга була иде», – дип тасвирлана Ага Базар Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрендә.

Ага Базар – X-XV гасырларда Болгар шәһәренең сәүдә-һөнәрчелек шәһәрчеге. Тарихчылар әйтүенчә, үткән гасырлардагы данлыклы Ага Базар хәзерге Болгар музей-тыюлыгы җиреннән 6 километр көнбатыштарак урнашкан булган. Заманында Куйбышев сусаклагычы ясалгач, ул урыннар хәзер су астында калган.

Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге белән берлектә XII–XIV гасырларда дан тоткан Ага Базарны торгызу омтылышы ясады – быелның 3 июлендә Изге Болгар җирендә Халыкара «Aga Bazar» этномәдәни фестивале узды. Ага Базар кабаттан Изге Болгар җиренең брендына әверелерме – анысын киләчәк күрсәтер. Һәрхәлдә биредәге сәүдә рәтләрендә үз продукциясен тәкъдим иткән 70тән артык һөнәрче бу омтылышны хуплады. Алар Ульяновск, Пенза өлкәләреннән,

Удмуртия, Башкортстан һәм Татарстан республикалары районнарыннан килгән иде.

Шунысы игътибарга лаек – гадәттә, төрле этномәдәни фестивальләрнең нигезен мәдәни чаралар тәшкил итеп, сәүдә рәтләре кушымта буларак күрсәтелә иде. Ә биредә сәүдә рәтләре төп чара булып, аңа «Uen Fest», «Иске Казан түгәрәк уены», «Күп аһәңле Татарстан» кебек популяр республика фестивальләренең программалары өстәлгән.

Фестивальне Спас муниципаль районы башлыгы урынбасары Сергей Тюнев һәм Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы директоры Рамил Җиһаншин ачты. «Без бу фестивальне беренче тапкыр уздырабыз. Ул ел саен узар һәм торган саен киңәя барыр дип өметләнәбез», – диде Рамил Җиһаншин.

«Бу фестиваль традициягә кергәч, туристларны да җәлеп итәр һәм аларның саны торган саен артыр», – диде Сергей Тюнев, тамашачыларны сәламләп.

«Ага Базар – иң зур базар дигән сүз. Бу Шәрыкъ базарларының иң көнбатышта урнашканы. Ә көнчыгышта базар товар сатып ала торган урын гына түгел, анда ял итәләр, тамак ялгыйлар, аралашалар. Хәзерге

сәүдә үзәкләрендә булганның барысы да Шәрыкъ базарларында, шул исәптән, безнең Ага Базарда да булган», – дип кунакларны сәүдә рәтләре белән таныштырды Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгының фәнни хезмәткәре, тарихчы Ренат Ваһапов. Ул яңартылган Ага Базарның хуҗасы, ягъни, Базар башы вазифасын үз өстенә алган иде.

Фестивальнең ике сәхнәсендә дә музыка яңгырап торды. Берсендә – Иске Казан түгәрәк уены фестивале кысаларында Татарстан районнарыннан килгән фольклор коллективлары чыгыш ясады. Икенчесендә – традицион музыка кораллары яңгырады. Кичке концерт программасында «IsTElek» иҗат берләшмәсе артистлары, фолк-фьюжн һәм электрон музыка жанрындагы композицияләр тәкъдим ителде.

Музей-тыюлык җирендә бу проект уңышлы эшләп китәрме – һөнәрчеләр моңа ышана. «Киләчәкбез», – ди алар.

КАЗАННЫ ГӨРЛӘТКӘН I ЭТНО-FASHION ФЕСТИВАЛЬ

Һөнәрчеләр ярминкәсеннән башлап, танылган дизайнерларның коллекцияләренә кадәр, киңкырлы программаны берләштергән «Яшәү стиле – Мәдәни код» дип аталган I Этно-fashion халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать фестивале быел Казанда 23-27 июль көннәрендә узды. Оештыручылар – Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге. Фестиваль берничә мәйданчыкта – Казан Кремлендә, Заманча сәнгать галереясендә, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданда үтте.

Фестивальгә Россиянең 32 төбәгеннән һәм якын чит илләрдән 400дән артык кунак – халык һөнәрчеләре, декоратив-гамәли сәнгать осталары, дизайнерлар, төрле иҗат берләшмәләре вәкилләре килде. Чараларда 15 меңнән артык кеше катнашты.

Кунакларны Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Мәдәният буенча комитет рәисе Елена Ямпольская, Татарстан Республикасының Мәдәният министры Ирада Әюпова, Россиянең Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының социаль товарлар сәнәгате үсеше Департаментының директор урынбасары Лилия Нургатина сәламләде.

Казанның Заманча сәнгать галереясендә исә декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре күргәзмәсе оештырылган иде. Анда 80 авторның 500дән артык иҗади эше тәкъдим ителде. Кунаклар шулай ук «Традицияләр һәм инновацияләр» дип аталган

иммерсив экспозиция белән дә таныша алды. Ул 4D форматында эшләнгән иде, ягъни, күргәзмәгә килүчеләр халык һөнәрчелеге эшләнмәләрен җитештерү процессы белән танышып, бу эшчәнлеккә хас булган исләрне тоеп, тавышларны да ишетә алды.

Фестиваль барган биш көн дәвамында галереяда иҗади очрашулар, түгәрәк өстәл утырышлары узды – дизайнерлар, сәнгать белгечләре, декоратив-гамәли сәнгать осталары тармактагы актуаль проблемалар хакында фикер алышты. Әлеге чараларда Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасы башлыгы Шамил Агеев, Казан дәүләт

мәдәният институты ректоры Роза Әхмәдиева һәм башка рәсми затлар катнашты.

Этно-fashion фестиваль кысаларында танылган 24 дизайнерның 27 коллекциясе тамашачыга тәкъдим ителде. Казан Кремлендә һәм Заманча сәнгать галереясендә Казан, Ханты-Манси округы, Башкортстан, Кырым республикаларыннан, Мәскәү, Иркутскидан килгән модельерларның этник стильдәге киемнәрен күрергә мөмкин иде.

Камал театры янындагы мәйданда биш көн дәвамында «Осталар ярминкәсе» эшләде. Ярминкә өчен махсус ясалган чатырларда 150 оста үз эшләрен тәкъдим итте. Анда Татарстан, Дагыстан, Башкортстан, Кырым республикалары; Калуга, Пенза, Мәскәү, Псков, Новгород, Ярославль, Иркутск, Түбән Новгород өлкәләре; Красноярск, Краснодар крайлары; Ханты-Манси округы; Санкт-Петербург һәм Мәскәү, Үзбәкстан һөнәрчеләре катнашты. Биредә зәркән эшләнмәләр, агачтан, күннән, тимердән, керамикадан, фарфордан һәм киездән ясалган әйберләр, кулдан чигелгән, тукылган эшләр, төрле сувенирлар, уенчыклар, этник кием табарга мөмкин иде. Һөнәрчеләр ярминкә белән генә чикләнмичә, илледән артык мастер-класслар да уздырды.

ТАТАРСТАНДА ЕЛ ҺӨНӘРЧЕЛӘРЕН БИЛГЕЛӘДЕЛӘР

Татарстанда быел беренче мәртәбә, «Яшәү стиле – Мәдәни код» I Этно-fashion халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать фестивале кысаларында, «Ел һөнәрчесе-2021» бәйгесе үтте. Бәйге Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы тарафыннан гамәлгә куелды. Оештыручысы – Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге. Конкурс республикада халык һөнәрчелеген саклау һәм үстерү максатларында үткәрелә. Киләчәктә ул ел саен узар дип көтелә.

Бәйге кагыйдәләре буенча, «Реконструкция», «Интерпретация» номинацияләрендә – 50 мең сумлык, «Сувенир» номинациясендә 20 мең сумлык сигезәр премия каралган иде.

Конкурста Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләреннән, шулай ук Буа, Апас, Минзәлә, Ютазы, Арча, Бөгелмә, Менделевск һәм башка республика районнарыннан халык һөнәрчелеге осталары катнашты. «Киез нур», «Сахтиан», «Саба сувенирлары», «Караван подарков», «Презент» оешмалары да үз эшләрен тәкъдим итте. Бәйгедә катнашу өчен барлыгы 128 гариза бирелгән иде: «Реконструкция» номинациясендә – 23 эш, «Интерпретация» – 64 эш һәм «Сувенир» – 41 эш.

Татарстан Республикасының Мәдәният министры Ирада Әюпова җитәкчелегендәге жюри бәйгегә тәкъдим ителгән эшләрне бик югары бәяләде. Җиңүчеләр Казанда 23-27 июль көннәрендә узган «Яшәү стиле – Мәдәни код» I Этно-fashion халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать фестивале кысаларында бүләкләнде.

ҖИҢҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

«Интерпретация» номинациясе:

Зөлфия Гыйльметдинова – Чигүле түбәтәй;

Хәмит Латыйпов – «Урман көе» панносы;

Наталья Уразгильдина – Йон келәм;

Руслан Сабиров – «Болгар кружкасы»;

Елена Флюр – «Нәфис фәрештә» күлмәге;

Әлфия Артемьева – Бизәкле читекләр;
Татьяна Табакова – «Татар бизәкләре» палантины.

«Сувенир» номинациясе:
Фәрит Вафин – Чигүле сөлге;
Александр Ванюков – Чүмеч;
Елена Егорова – Рушник;
Александр Стрелов – Сөт кувшины;
Рәмзия Фәттахова – Казан калфагы;
Айрат Солтанов – «Биләрдә көз» сумкасы;
Ольга Смирнова – «Шамаил» триптихы.

«Реконструкция» номинациясе:
Раушания Полосина – Алтын чигүле татар сөлгесе;
Лилия Сафина – «Гөлчәчәк» җыелмасы;
Светлана Прокопьева – «Дәү әни келәме»;
Рөстәм Шамсутов – «Тормыш агачы» панносы;
Надежда Шәйхисламова – Чигүле калфак;
Рәфкат Мөхәммәтшин – Коръән савыты;
Айгөл Садриева – «ASLAH» сумкасы;
Геннадий Мальгин – Агачтан бакча дизайны әйберләре.

КАЙБЫЧТА «КИЧКЕ УЕН» + «UEN FEST»

Олы Кайбыч авылының «Имәнлек» Үзәк паркында алтынчы ел рәттән кичке уеннар уздырыла. Быел ул 13 августта үтте.

«Кичке уен» дип аталган халык бәйрәменең тамырлары борын заманнарга барып тоташа: кич белән татар авылларының кызлары һәм егетләре елга буена җыелып уйнаганнар, гармунга кушылып җырлаганнар, таган атынганнар. Кичке утырулар рус һәм чуваш авылларында да булган.

Хәзер Кайбычта уздырыла торган «Кичке уен»нарның төрле халыкларны – шушы район җирлегендә яшәүче татар, рус, чуаш, керәшен халкын бер мәйданга җыйган үз программасы бар. Быел да биредә традицион уен кораллары белән төрле халыкларның көйләре яңгырады, милли җырлар башкарылды. Концерт программасында «ZAKARIA» күпмилләтле фольклор төркеме, Базарбай Бикчәнтәев, Айдар Рәкыйпов, Вадим Фәтхинуров чыгыш ясады.

Фестиваль кунакларын төрле милләтнең милли ризыклары белән сыйладылар, аттракционнар, шулай ук декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре куелган сәүдә рәтләре эшләде.

Иң күңеллесе – Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның «Uen Fest» II Төбәкара традицион уеннары фестиваленең зона этабы да «Кичке уен» бәйрәме кысаларында – Олы Кайбыч авылының «Имәнлек» паркында узды (I зона этабы бу елның 1-2 июль көннәрендә, Әлки районының «Яшь имәннәр» балалар лагеренда үткән иде). Фестиваль җиңүчеләрен Кайбыч муниципаль районы башлыгы Альберт Рәх-

мәтуллин һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин биредә – бәйрәм үткәрелә торган паркта бүләкләде.

Чараны оештыручылар: Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты һәм районның Мәдәният бүлеге.

«ТҮГӘРӘК УЕН» ЯШИ – РӘХӘТЛӘНЕП КАРАДЫК»

Быелның 28-29 августында башкалабызның «Чулпан» мәдәният үзәгендә XIII «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивале узды. «Быел ул Самара өлкәсендә үткәрелергә тиеш иде, әмма эпидемиологик вәзгыят аркасында анда үткәрә алмадык. Бәйрәмнең Казанда узуына коллективлар бик шат – Казанга сөенеп киләләр», – ди Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге директоры Алсу Мифтахова.

Фестивальдә утызлап коллектив катнашты. Алар арасында Башкортстан, Чиләбе, Киров, Төмән өлкәләре, Пермь крае һәм башкалар бар.

«Түгәрәк уен» татар фольклоры фестиваленең 2021 елгы 1 нче дәрәҗә лауреатлары:

– Фольклор ансамбле – Башкортстанның Бакалы районы Яңа Балыклы авылы «Туганай» фольклор коллективы. Җитәкчесе: Люция Вафина;

– Вокаль ансамбле – Чиләбе өлкәсенең Нязепетровск районы Арыслан авылы «Ләйсән» халык фольклор ансамбле. Җитәкчесе: Роза Мөхәрәмова;

– Инструменталь ансамбль – Төмән өлкәсенең «Чыңгыз-Тура» коллективы. Җитәкчесе: Зилә Йосыпова.

«Бүгенге вәзгыяттә Татарстаннан читтә иҗат иткән коллективларның килүе дә сөендерә. «Түгәрәк уен» яши – рәхәтләнеп карадык. Катнашучылар әзерлекле, әмма эпидемиологик вәзгыят белән бәйле рәвештә әзеклек булып тору үзен сиздертә. Мин үзем аеруча яратып Бакалы районыннан килгән керәшен ансамблен карадым. Алар турында күп ишеткән идем, ниһаять күрдем», – диде жюри әгъзасы, фольклор белгече, профессор Алсу Еникеева.

* * *

Укучыларыбызга «Түгәрәк уен»ның лауреаты булган «Туганай» ансамблен тәкъдим итәбез. Аның белән безне Яңа Балыклы авылының иң өлкән кешеләренең берсе булган Клара Федоровна Топоркова таныштырды. Быел аңа 83 яшь тула. Үзе әйтмешли, ансамбльгә әле 16 ел гына йөри. Ансамбль чыгышларында ул үзе язган такмакларны башкара.

– «Туганай» керәшен ансамбле тарихы 1972 елдан башлана. Анда безнең агайлар, әниләр, апалар йөргән, хәзер күчә-күчә безгә дә килеп җитте. Ансамбльнең бүгенге көнгә килеп җитүендә безнең Каменевлар нәселенең роле зур. Үзебез шушы яшькә

җитсәк тә, әниләрнең гореф-гадәтләрен ташлыйсы килми. Аларның җырларын кабатлагач, яшәреп киткән кебек булабыз. Авыл халкы киләчәктә дә бу ансамбльне җуймас дип ышанам. Бездә бакча балаларына да ансамбль җырларын өйрәтеп бардылар, хәзер дә өйрәтәләр», – ди Клара Топоркова.

Ансамбльдә катнашучылар киҗе-мамыктан сугылган борынгы киемнәрдән, күкрәкләре тәңкәләрдән җыелган түшлек белән ябылган, башларында – сүрәкә.

– Бу киемнәребезгә 150 елдан артык. Минем өстәге күлмәк әбиемнең чаршавы булган. Аны әтиемнең тутасы саклап калган. Пенсиягә чыгып коллективка катнашкач, чаршаудан үземә күлмәк тектем. Үзем исән чагында җаным кебек саклап торам инде, – ди Клара Топоркова. – «Түшлек» дип аталганнарын тәңкәләрдән ясыйбыз. Элеккеге тәңкәләр калмаган бездә, ашар өчен сатып бетергәннәр бит инде. Моны иске акчаларны җыеп үзебез ясадык. Башка кигәнебез «сүрәкә» дип атала. Бу сүрәкәләрне элек әниләр, әбиләр чигеп эшләгәннәр. Андыйлар бик аз калган инде. Хәзер үзебез ялтыравыклар белән ясыйбыз, яшьләргә дә өйрәтәбез. Әлегә коллективны шулай алып барабыз.

Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

Резеда ШӘРИПОВА,
Азнакай

«ЧАТЫР ТАУ – *туган якның кыйбласы, шәмаиле!»*

ҖӘЙНЕҢ МАТУР БЕР КӨНЕНДӘ АЗНАКАЙДА УНБЕРЕНЧЕ ТАПКЫР «ЧАТЫР ТАУДА ҖЫЕН» ИСЕМЛЕ ТӨРКИ ХАЛЫК ИҖАТЫ ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ. АНДА 40 КА ЯКЫН ФОЛЬКЛОР КОЛЛЕКТИВЫ КАТНАШТЫ. ФЕСТИВАЛЬ ТРАДИЦИЯ БУЕНЧА ЧАЛ ГАСЫР ТАРИХЫН ЧАГЫЛДЫРГАН ТЕАТРАЛЬЛӘШТЕРЕЛГӘН ТАМАША БЕЛӘН БАШЛАНЫП КИТТЕ.

Фестивальне Азнакай муниципаль районы башлыгы Марсель Шәйдуллин ачты. «Азнакайның мәгърур Чатыр тавы җыр-моңга гашыйк, халык җәүһәрләрен яңартып-саклап яшәүче иҗат коллективларын тагын үз итәгенә җыйды. Ул дүртенче ел халыкара дәрәҗәдә уздырыла. Фестиваль милләтләр арасында дуслыкны ныгытуда, туганлык, бердәмлек хисләрен арттыруда, ата-бабаларыбызның йолаларын, инде онытыла барган матур көй-моңнарын яшь буынга җиткерүдә зур роль уйный. Ерак араларны якын итеп килгән барча кунакларга ихлас рәхмәтемне җиткерәм. Алга таба да күркәм

гореф-гадәтләребезне, телебезне саклап, туган җиребез белән горурланып, дус булып яшик», – диде ул.

Фестивальдә якташларыбыз – Татарстанның халык артисткасы Зәйнәп Фәрхетдинова һәм Татарстанның атказанган артисты Равил Галиев, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге хезмәткәрләре Рәзинә Исмәгыйлева, Фәния Лотфуллина катнашты.

– Туган җиребез белән горурланабыз, яратып искә алабыз, бәйрәмдә катнашуым белән мин бәхетле. Үткәндә дә, сүткәндә дә Чатыр тавына карап китәм, аңа сәлам юллыйм. Бүгенге җыен безне тагын да бер югарырак берләштерү ноктасына менгерсен, – диде Зәйнәп Фәрхетдинова.

Чатыр тау итәгендәге мәйданда төрки халыкларның көнкүрешен чагылдырган «Сабыйлар аланы», «Чәк-чәк аланы», «Халыклар дуслыгы урамы», «Кул эшләре аланы», «Яшьләр аланы» мәйданчыклары оештырылган иде. Халык биредә кул эшләре осталарының күргәзмәләре, милли ашлары белән танышты, авыз итеп карады.

Фестивальдә Азнакай, Алексеевск, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Буа, Балык Бистәсе, Зәй, Кукмара, Лениногорск, Минзәлә, Саба, Сарман, Чирмешән, Ютазы, Яңа Чишмә, Түбән Кама районнарыннан, Чаллы шәһәреннән, Башкортстан Республикасының Октябрьск, Туймазы шәһәрләреннән, Оренбург, Самара өлкәләреннән килгән фольклор коллективлары, шулай ук «Alpar» татар инструменталь фолк-төркеме (Казан шәһәре) һәм «Бишбармак» оркестры (Уфа шәһәре) чыгыш ясады. Халык милли уеннарда, мастер-классларда катнашты.

Белешмә: Чатыр тавы – Татарстанның иң биек ноктасы, диңгез өстеннән биеклеге 334,5 метр тәшкил итә. Археологлар раславынча, аңа 200-250 миллион еллар чамасы.

Чатыр тавы – табигать тыюлыгы. Биредә сирәк очрый торган бөҗәкләр яши һәм үсемлекләр үсә, аларның 50 төре Кызыл китапка кертелгән. Монда шулай ук суырлар колониясе яши. Аларның саны 7 меңгә җитә.

Чатыр тавы куенынннан шифалы сулы чишмәләр саркып чыга. Борынгылар аның суына ерак-ераклардан килә торган булган.

Әйтерсең лә, Чатыр тавының рухы уянды – бу көнне җәй буена тансыклаган шифалы яңгыр да явып узды. Коллективлар яңгыр астында да биеп-җырлап, күңел ачты, алар үз иҗатлары белән халкыбызның бай мәдәни мирасы яшәвен һәм яшәячәген раслады.

МИСТИКА: ЧАТЫР ТАУНЫҢ ИЛАҺИ КӨЧЕ

Азнакайлылар Чатыр тауның илаһи көченә ышана. Монда әйтелгән теләкләр кабул була, диләр. Хәтта күктән тауга сибелгән «серле нурлар»ны фотосүрәткә төшерүчеләр дә бар

СПЕЛЕОЛОГИЯ: СЕРЛЕ МӘГАРӘЛӘР

Биредә үзенең гаскәрләре белән Емельян Пугачев та торган диләр. Тау мәгарәләрендә яугирләрнең эзләре озак сакланган. Хәзер инде бу куышларга үтеп кереп булмый, гасырлар дәвамында алар иңгән, юллары капланган.

1771-1774 елларда бу яклардан немец сәяхәтчесе Петр Симон Паллас та узган һәм Чатыр тавын үзенең елъязмаларына кертеп калдырган. Ул биредәге бакыр рудниклары турында тәфсилләп яза.

ФОЛЬКЛОР: ЧАТЫР ТАУ ҖЫЕННАРЫ

Элек-электән монда җыеннар узган. Анда аксакаллар ил-көн хәлләрен сөйләшкәннәр, киңәш-табыш итешкәннәр, шул чорларның кадагында булган мәсьәләләрне уртага салып хәл иткәннәр.

Әби-бабайлар сөйләве буенча, Чатыр тавында узган гасырларда ук бәйрәмнәр оештырганнар. Якын-тирә авыллардан бәйрәмчә киенгән кызлар-егетләр май аеның һәр пәнҗешәмбесендә «Чатыр атнасы»на җыелганнар. Алар бер-берсенә бүләкләр ясашып, җырлап, биеп, уйнап күңел ачканнар.

Биредә «Чатыр бәйгесе» дә узган. Июнь урталарында тирә-юньнең иң яхшы чаптарлары ат чабышларында катнашкан.

БҮГЕНГЕ ЧАТЫР ТАУ: ОЧАР КАНАТЛАР

Чатыр тавы парапланеризм белән шөгыльләнү өчен уңайлы урын. Шуңа да күрше-тирә районнардан гына түгел, республикалардан да бирегә спортның әлеге төрен яратучылар килә. Шулай ук Азнакайның Данис Мусин җитәкчелегендәге «Патриот» клубы да бу юнәлештә балалар һәм яшьләр арасында эш алып бара.

«ҖАНАШЫМ» – БӘЙРӘМ КҮРКЕ

Азнакай шәһәр-район мәдәният йортында эшләп килүче «Җанашым» ансамбле 2017 елдан бирле «Россия Федерациясенең атказанган халык иҗаты коллективы» дигән мактаулы исемне йөртә.

Белешмә: *Коллектив 2006 елда – ул чакта Мәдәният йорты директоры булып эшләгән Зөлхия Миңнеханова тәкъдиме белән оеша. Биредә борынгы җырларны башкару һәм кубызда, курайда уйнау осталыгы белән тамашачыны таң калдырган Гөлсинә Хафизова (хәзерге көндә район Мәдәният идарәсе җитәкчесе), күп кенә татар җырларына яңа сулыш өргән автор-башкаручы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Ландыш Шәрәфиева (хәзер район Мәдәният йорты директоры), үз куллары белән ясаган кубыз-курайларда, сорнайда, таш сыбызгыда уйнаучы оста куллы Әҗүәт Җиһаншин, гармунда, баянда, тальянда өздереп уйнаучы Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәйрүзә Гатауллина, Фәйзулла Туишев исемендәге республика гармунчылар фестивалендә берничә тапкыр лауреат исемен яулаган Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Атлас Хуҗин, татар халык җырларын тирәнтен башкара торган Фәния Усманова, Гөлүзә Нургалиева, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Зөлхия Миңнеханова кебек талант ияләре туплана. Флера, Камил, Мөнирә, Маргарита, Раушания, Светлана, Әлфия, Лилия коллективка яңа рух, яшьлек дәрте алып килә.*

2006 елда ук ансамбль республика халык иҗаты фестиваленең зона конкурсында катнашып, гала-концертта чыгыш ясый. Бүген инде «Җанашым» – үз йөзен булдыр-

ган, горурланырлык уңышларга ирешкән ансамбль. Менә аларның кайбер җиңүләре:

– 2010 елда Сыктывкар шәһәрендә узган VII төбәкара «Завалинка» фестивалендә «Милли традицияләрне саклау өчен» номинациясендә I дәрәҗә лауреат;

– 2012 елда мәдәният-сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен районның Мәхмүт Хәсәнов исемендәге премиясе;

– 2013, 2016 елларда Чабаксар шәһәрендә уздырылган «Россия – без бергә» фестивалендә I дәрәҗә лауреат;

– 2013 елда «Казан Кремле» музей-тыюлыгында үткән «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклор фестивалендә катнаша;

– 2012 елда ансамбль беренче тапкыр чит илгә чыгып, Төркиянең Тарсус шәһәрендә чыгыш ясый (Азнакай белән Тарсус күп еллар дәвамында тугандаш шәһәрләр булып, мәдәни бәйләнештә яши);

– 2017 елда Казанда «Этномириада» халыкара фестивалендә «Каурый сыдыру өмәсе» йоласын күрсәтеп, I дәрәҗә лауреат;

– 2018 елда «Тирән тамырлар» көньяк-көнчыгыш төбәге фестивалендә «Бахатай» (богатый) борынгы йолаларның берсе белән катнашып, лауреат дипломына лаек була.

2014 елда Венгриядә узган төрки халыклар Корылтаенда Татарстан Республикасы исеменнән чыгыш ясау да алар өчен җаваплы бер миссия була. Корылтайда 170 меңләп кеше катнаша. Дөньяның төрле почмакларыннан килгән кардәшләр белән аралашып, аларның җыр-моңнарын тыңлап, милли киемнәрен күреп, онытылмас тәэсирләр алып кайта алар аннан. Казахстанның танылган «Туран» дәүләт фольклор ансамбле Корылтайны ябу тантанасында бергә чыгыш ясау өчен «Җанашым»ны сайлый.

Күптән түгел генә коллектив Чувашстан Республикасы көненә багышлап уздырылган «Россия чишмәләре» («Родники России») фестивалендә катнашты.

«Бүгенге көндә коллектив иҗади эзләнүдә. Әби-бабайлардан мирас булып калган һәм үзенең төсен, моңын, үзенчәлеген югалтмаган аһәңле җырларыбыз, биюле такмакларыбыз, йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез җитәрлек. Без шуларны табып, композицияләр ясыйбыз. Башка төбәкләрдә яшәүче татарларның да биюләрен, җыр-бәетләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнеп сәхнәгә чыгарга әзерләнәбез. Бу эштә, билгеле, тормыш иптәшем, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ансамбльнең аккомпаниаторы Ригель Әхмәтҗановның ярдәме зур», – ди ансамбль җитәкчесе Гөлфия Әхмәтҗанова.

Фоторәсемнәр aznakayevo.tatarstan.ru сайтыннан

Лилия САТТАРОВА,
сәнгать белгече, Татарстан Республикасы Милли музееның тупланмалар буенча җаваплы генераль директор урынбасары

КОРЪӘН савытлары

КОРЪӘННЕҢ МИНИАТЮР БАСМАЛАРЫ ЯКИ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ ҺӘМ ДОГАЛАР ӨЧЕН САВЫТЛАР ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ МУЗЕЕНЫҢ ШАКТЫЙ ЗУР ТУПЛАНМАСЫН ТӘШКИЛ ИТӘ. АЛАРНЫҢ КҮБЕСЕ АНДРЕЙ ФЕДОРОВИЧ ЛИХАЧЕВ ҺӘМ ЛЕОН СИКЛЕР ҖЫЙГАН ЗӘРКӘН БИЗӘНҮ ӘЙБЕРЛӘРЕНЕҢ ЗУР КОЛЛЕКЦИЯЛӘРЕ БЕЛӘН БЕРГӘ КЕРГӘН.

Борынгы фоторәсемнәрдә күрәбез – озын затлы күлмәк кигән бай татар хатыннарының зәркән бизәнү әйберләре арасында догалар салынган футляр да булган, алар аны озын чылбыр белән түш өстендә йөрткән. Элегрәк бу тартмачыклар күкрәк бәйләвеченең бер өлеше булып торган дип тә раслый алабыз. Музей тупланмаларындагы хәситәләргә дога савытлары беркетелгән, аларда гарәпчә язылып, пөхтә итеп бөкләнгән кәгазь битләре саклanган. Һәрбер ювелир тартмачыкларның эчке ягында металл элмәкләр бар – чылбыр яки бау шулар аша үткәрелгән.

Кечкенә дога савытларының нинди генә формадагысы юк – квадрат, турыпочмаклы, сигезпочмаклы, өчпочмаклы, түгәрәк һәм овал рәвешлесе дә бар. Алар көмештән ясалган, алтын белән йөгертелгән, нәфис ояларга утыртылган асылташлар белән бизәлгән. Дога савытларының үлчәме төрлечә. Әйтик, 200 грамм авырлыктагы шактый эре футляр – капкачы кайтарылып ачыла торган көмеш тартма күзгә ташлана. Аның чәчәк таҗлары рәвешендәге бизәкләре дә, язуы да чокып эшләнгән, биш сердолик каш та куелган. Капкачының өске өлешенә «Бисмилла» язылган, үзәктә – Аллаһның 99 гүзәл исемнәреннән берничәсе – Әл-Кави – Кодрәт иясе, Әл-Фәттах – Аңлатучы, Әл-Гани – Мохтаҗсыз, Әр-Раззак – Булучe дип язылган. Аста гарәп цифрлары белән дата күрсәтелгән – 1846 ел. 13,3х13,3х1,9 сантиметр үлчәмле бу футлярда аның иясе яраткан текстларны – Пәйгамбәр хөрмәтенә касыйдәләр яки догаларны саклагандыр, уң кул ягыннан күкрәк бәйләвеченең аскы читенә тегеп куелган булырга мөмкин.

Икенче бер түгәрәк тартмачыкны да шул ук оста эшләгән булуы мөмкин – бизәлеше охшаш. Түгәрәк көмеш футляр-медальоннар нәфис формалары һәм җиңел челтәр бизәкләре белән аерылып тора – бу татар филиграненың иң гүзәл үрнәкләреннән

берседер, мөгаен. Футлярның гөмбәзсыман капкачлы түгәрәк савыт формасы кыйммәтле кульъязма Коръәннәрне махсус савытларда саклау традицияләрен яңарта кебек. Андый металл һәм агач тартмачык-махфазаларның, мәсәлән, Госманлы Төркиясендә булуы билгеле: аларның сигез кыры нәфис гөмбәзгә җыелган.

Татар бизәнү әйберләре тупланмасында XVIII-XIX гасырлардан килгән берничә челтәрләп эшләнгән түгәрәк зәркән футляр саклана. Аларның декоратив чишелеше охшаш: челтәрле капкач, филигрань яки чокып ясалган төпле, өч яки биш асылма бизәк чылбыр белән тоташтырылган. Челтәрле бөдрәләрдән ясалган бөҗра бизәкле капкач хасил итә, аның эчке контуры җиде яки ун таҗлы чәчәктән торган «гөмбәз»гә теләлә.

А.Ф. Лихачев коллекциясеннән челтәрләп эшләнгән җиңел тартмачык (нибары 28 грамм) – аерым төркем булып торган өч артефактның берсе. Капкачының гөмбәзе җиде таҗ яфракчыгы булган, арасына серкәчкә охшаш нәзек элмәкләр беркетелгән чәчәктән тора. Капкачтагы фирүзә каш тимерчыбыктан ясалган түгәрәк кысага утыртылган. Сигез кечерәк түгәрәк кыса, филигрань бөдрәләрдән ясалып, гөмбәзне әйләндереп алган алкага урнаштырылган. Элеп куя торган ике алка, шулай ук өч кечерәк алка тартмачыкның кырына беркетелгән, аларга нәзек чыбыклардан ясалган ике чылбыр тоташа.

Челтәрле тартмачыкның тагын бер төрен бүлеп карарга мөмкин, боларның капкач декоры катлаулырак: алка һәм гөмбәз тоташкан урын филигрань бөдрәләр – фестоннар белән ясалган, аларның саны 18гә җитә. Шуның аркасында тартмачыкның диаметры 6 сантиметрга җиткән, футляр шактый саллы күренә, авырлыгы 100 грамм.

Капкач гөмбәзен тәшкил иткән ун таҗ яфракчыклы филигрань чәчәк гаҗәеп матур, ул ун фестон белән әйләндереп алынган һәм куыш шар белән төгәлләнгән. Төбе тышкы яктан үзәк медальон тирәли тезелгән язулар белән бизәлгән.



гән. Тупланманың кайбер әйберләрендә «В.С./1861», «84» келәймәсе бар. Шуларның берсе – алтын йөгертелгән нәфис футляр, аның бизәлешендә шәрыкъ һәм көнбатыш традицияләре кушылган: иркен граверланган үсентеләр фонында рельефланган гарәп язуы рокайль мотивлы кысаларга урнаштырылган. Берничә футлярның капкачы бизәкләренең стиле буенча Европа көмешчеләре эшен хәтерләтә, икенче бер миниатюр Коръән савыты ташлар яки төсле пыяла каш белән бизәлгән. Рельеф бизәге гирлянда кебек тоташтырылган чәчәкләр һәм бөреләрдән, яки гаҗәеп яфраклардан, бөдрәләрдән тора. Барлык композицияләр көзгеле симметрия буенча төзелгән.

Түгәрәк тартмачыкларны бизәү тагын бер зәркән техникасын – ярмалау ысулын куллану юлы белән үсеш кичергән. Мәсәлән, бер мисал – ун таҗ яфракчыклы чәчәкне 13 фестон әйләндереп алган, филиграньнең барлык бөдрәләре төрле зурлыктагы ярмачыклардан тора. Капкачның тышкы алкасының бөдрәләре эчендә ярмалы вак шарчыклар алты таҗ яфракчыклы чәчәкләрдәй тезелгән. Музей тупланмасындагы икенче тартмачык кебек, әлеге футлярның төбе челтәрле филиграньнан ясалган.

Төрле формадагы кыйммәтле зәркән футлярлар хәлле кешеләр заказы буенча әзерләнгән. Күп кенә үрнәкләргә осталарның монограммалы тамгасы сугылган, елы һәм көмешнең пробасы күрсәтел-

Бездә сигез почмаклы футлярлар да бар, аларның үлчәме дә зур түгел – 5,8х5,5х1,8 сантиметр, авырлыгы 40 грамм, әлеге үзенчәлекле тартмачыклар Һиндстанда басылган сигезпочмаклы миниатюр Коръәннәр өчен ясалган. Аларның берсе Л. Сиклер тупланмасыннан кергән. Шарнирга беркетелгән капкач өскә таба ачыла, капкачтагы дүрт юл язу шома тасмалар белән аерылган ике бордюрдан торган бизәкле кысаларга кертелгән. Бизәкле язу Коръән савытының иясе Мөхәммәт Хөсәен хатыны булуын искәртә.

Сигез почмаклы Коръән савытлары чын зәркән бизәк буларак ясалган – аны татар зәркәнчеләре нәкышь техникасы белән башкарган. Коръән савытын ясаган оста язу фонын һәм бордюрны канфарение техникасы белән вак төрткеләп тутырган, аның өстендә шома хәрефләр һәм орнамент элементлары ярылып ята. Зигзаг сыман сызыклар кебек тар бордюрлар да, тешле кырыйлы юллар да үзенчәлекле. XIX гасыр урталарындагы кайбер үрнәкләрнең бизәгендә нинди дә булса мотивны аерып алуы да кыен, орнамент гарәп язуының стилизацияләнгән хәрефләрен хәтерләтә. Бу футляр, һичшиксез, элегант бер бизәнү әйбере, мөгаен, ул чылбыр белән түшкә асып куелгандыр. Тартмачыкның өске кырына беркетелгән ике җыйнак кына элмәк шуны раслый, ә каршы як кырында йозагы бар.

20-24 нче битләрдә – миниатюр Коръәннәр һәм догалар йөртү өчен көмеш савытлар (Татарстан Республикасы Милли музее тупланмаларыннан)

Бергәләп бизибез!



Зәлия БРУСЬКО,
филология фәннәре кандидаты

«Әлли-бәлли, бәлли-бәү...»

БИШЕК ҖЫРЛАРЫ КӨНКҮРЕШ ҺӘМ СӘНГАТЬНЕҢ СИНТЕЗЫН, СӘЛАМӘТЛЕК ҺӘМ ТОРМЫШ ТУРЫНДА ШИГЪРИ-СӘНГАТИ ГОМУМИЛӘШТЕРҮНЕҢ БЕРЛЕГЕН ТӘШКИЛ ИТӘ. БИШЕК ҖЫРЛАРЫ – ХАЛЫК ПЕДАГОГИКАСЫНЫҢ ОЛЫ МИРАСЫ, ЧӨНКИ УЛ ДАИМИ КАЙГЫРТУ, НАЗ, ИРКӘЛӘҮ ТАЛӘП ИТКӘН САБЫЙДАН КЕШЕ ТӘРБИЯЛӘҮНЕҢ ХАЛЫК ТӘҖРИБӘСЕНӘ БАРЫП ТОТАША. БИШЕК ҖЫРЛАРЫНЫҢ ТӨП ЭЧТӘЛЕГЕ АНАНЫҢ БАЛАСЫН ЯРАТУЫННАН, АНЫҢ БӘХЕТЛЕ КИЛӘЧӘГЕ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАРЫННАН ТОРА ИКӘН – БУ ЮККА ГЫНА ТҮГЕЛ ЛӘБАСА.

Илсинә БӘШИРОВА (11 яшь) рәсеме,
Казан, 1 нче балалар сәнгать мәктәбе укучысы

Бишек җырын, кагыйдә буларак, балага әнисе (яки әбисе) җырлавы әһәмияткә ия, чөнки тормышның бу этабында бала өчен ана дөньяның зур бер өлешен тәшкил итә. Ничәмә-ничә гасырлар дәвамында бишек җырлары аналарның хисләрен чагылдыра, тәрбия һәм этник чыганакларга бәйләү ысулы булып тора. Бишек җырлары татарларның традицион мәдәниятендә үзенең лаеклы урынын тота. Аларның табигый кулланылышы да искә алына – ана баласына җырлаган кебек, җырлар балалар тирәлегендә уен буларак та кулланыла, әлеге халык иҗаты жанрына караган конкурсларда һәм кичәләрдә дә яңгырый.

Бишек җырларын өйрәнүче галимнәр аларны төркемнәргә бүлеп карый, нигезен тәшкил иткән мотивларын ачыклый, функциональ бурычларын билгели. Бишек җырларын өйрәнүче рус галиме А.Н. Мартынова классификациясенә караганда, алар ике төркемгә бүленә: традицион (буыннан буынга күчеп килгән) һәм традицион булмаган (язма әдәбияттан һәм халык авыз иҗатының башка жанрларыннан алынган). Татар балалар фольклорын өйрәнгән галим Р.Ф. Ягъфәров әлеге классификациягә таянып, тагын бер төркемне бүлеп чыгара – совет чоры бишек җырлары. Татар бишек җырларының бүгенге көнгә кадәр даими тулыланып торуын да әйтергә кирәк. Бүгенге техник мөмкинлекләр (телевидение аша трансляцияләү, төрле социаль челтәрләр) аларны бик тиз популярлаштыра, алар традицион җырлар белән бергә башкарыла башлый.

Татарларның бәби табу йолалары структурасында бишек җырларының төп функциясе – утилитар-көнкүреш функция – бәбине бишек тирбәлешенә туры килгән салмак кына ритм һәм монотон көй белән тирбәтеп йоклату. Әмма бу функция үзе генә башкарылмый. Ул табигый рәвештә өйрәтү, тәрбияләү, таныштыру, теләк теләү, куркыту һәм башка функцияләрне үз эченә ала. Гомеренең беренче көннәреннән үк бала бишек җырлары аша үз халкының мәдәнияте белән таныша – туган телен, көен ишетә, көнкүреш үзенчәлекләрен белә, тирәлекне таный, якын кешеләренең хисләрен аңларга өйрәнә. Нәкъ менә бишек җырлары ярдәмендә сабый үзенең иң яхшы шәхси сыйфатларын формалаштыру кодировкасы аша үтә. Бу яктан караганда, бишек җырлары геннар белән салынган мөмкинлекләрне, этник кодларны ача торган, кешеләрнең этник үзаңын беркетә торган беренче корал.

Баланы дөнья белән таныштыру йомшак кына, салмак кына бара. Бишек җыры көйле-көйле ана гадидән катлаулыга, якыннан еракка күчә, кечкенә кешенең башына зур дөнья турында беренче гыйлемнәрне сала.

Әлли-бәлли ит, балам,
Сине бишеккә салам.
Сине бишеккә салгач та,
Үзем эшемә барам.

Балага җыр сүзләре аңлаешсыз булса да, алар бик ачык итеп бирелә – баланың аңында тормыш чынбарлыгы күзаллана – якыннарының көндәлек эшләре һәм мәшәкатьләре, тормышның тыныч агышы аның йокысына бәйле.

Ана ихлас күңелдән башкарылган бишек җырларына үз хисләрен, теләкләрен һәм баланың киләчәгенә бәйле борчуларын сала.

Әлли-бәлли-бәү, бәү,
И җомырым, җомырым,
Саулык-сәламәтлек белән
Озын булсын гомерең.

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәктәпләргә китәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Үзләренең композицион, эмоциональ агымы буенча кайбер бишек җырлары вакыйгалар агышын уңай якка үзгәртергә омтылган әфсен сүзләрен хәтерләтә. Әйтик, кыз баланы йокларга салганда аның вакытында кияүгә чыгып, бәхетле гаиләдә яшәвен телиләр.

Йокла, кызым, йокла, кызым,
Йокла, кызым, йом күзең.
Үсеп матур кыз булган соң,
Кияү табарсың үзең.

Алдагы куплет та шул ук принцип белән төзелгән:

Бүлли-бүл, бүлли-бүл,
Бүдәнәдәй түлле бул.
Карчыгадай күзле бул,
Адәм тапмас сүзле бул!

Мондый эчтәлекле бишек җырлары теләкле җырларга якын тора. Алар балага кагылышлы теләкләрнең кабатлануына корылган. Һәр строфа билгеле бер теләкне атый, ахыргы сүзләрнең кабатланышы теләгән нәтиҗәне раслау булып яңгырый. Җырда бүдәнә образы да очраклы түгел. Татарлар аны күп бала китерә торган дип белә. Ишле гаилә булдыра алу кеше өчен бик әһәмиятле сыйфат булып саналган. Шулай итеп, кече яшьтән үк кыз баланың аңына ишле гаилә турында төшенчә кертеп урнаштырыла.

Ир балага багышланган куплетларда гаилә булдыру идеясе күренә, ир бала нәсел дәвамчысы итеп күзаллана:

Улым, улым, ул кеше,
Улыма кирәк кыз кеше.
Кода булып йөрүләрне
Булдыра алмый күп кеше.

Татар бишек җырларында чагыштырулар зур урын алып тора. Алар баланың төп үзенчәлекләренә игътибар иттерә, башкаручының хисләрен белгертә, шулай ук баланы матурлыкны тоярга өйрәтә. Бала кошлар («сандугачым»), чәчәкләр («гөлием»), җимеш агачлары («кара бөрлегән»; «вак алмам»), күк җисемнәре («йолдызым»; «кояшым син, аем син») һәм башкалар белән чагыштырыла.

Кошлар белән бергә татар бишек җырларында кайбер хайваннарның образлары да бар, мәсәлән, кәҗәләр, бүреләр, аюлар һәм башкалар. Текстта әлеге хайваннарга бәйле вакыйгалар тасвирлана. Р.Ф. Ягъфәров фикерчә, бу образлар баланың игътибарын тышкы факторлардан читкә юнәлтү функциясен үти. Шул ук вакытта йокламыйча көйсезләнгән баланы куркытып та ала:

Әлли-бәлли, Бәхтияр,
Ызба артында бүре бар.
Чәркә кебек күзе бар,
Елаганны кереп ал.

Әлеге бишек җырлары арасында «бүкәй» дип аталган персонаж катнашындагылары да бар. Төрки, славян, фин-угор халыкларына төрле атамалар аша билгеле («bükä» – борынгы төрки, «моохуй» – якут, «мокай» – шор, «бапак» – башкорт, «бука» – рус, «моко» – удмурт) мифологик персонаж көйсез баланы куркыту (дөресрәге, кисәтү) өчен кулланыла. Барлык мифологик персонажлар кебек, бүкәй параллель дөньяга карый, шунлыктан тыңлаусыз баланы «урлаучы» булып сурәтләнә:

Әлли-бәлли-бәү итә,
Улым йокыга китә.
Улым йокыга китмәсә,
Бүкәйләр алып китә.

Галимнәр фикеренчә, мондый куркыту баланың тәртибен рәтли һәм аны йоклата.

Бу персонажның бишек җырлары белән генә чикләнмәвен билгеләп үтәргә кирәк. Шук, тыңлаусыз баланы ата-анасы «бүки», «бүки тәпи» алып китә дип куркыталар. Халык бу персонажны кечерәк буйлы җонлы зат – ярым кеше, ярым җанвар буларак сурәтли. «Бүкәй» сүзенең этимологиясен галимнәр «бүкә» дигән борынгы төрки персонажга бәйләп аңлата, бу тәрҗемәдә «зур елан» мәгънәсен бирә.

Галимнәр борынгы бишек җырларында рифма булмауга игътибар иткән, ул бер төрле сүзләрнең кабатлануына, яисә этәргеч ымлыкларга алыштырылган. Татарларның бишек җырларында нәкъ шуны күзәтәбез дә инде. «Бүлли-бүл, бүлли-бүл», «әллү-бәл-

лү», «әлли-бәлли-бәү» кебек кабатлаулар текстка бертөрлелек бирә, баланың тынычланып йоклап китүенә китерә.

Совет чорында иҗат ителгән бишек җырларына Ватанга хезмәт итү, дошманнардан туган җирне саклау, халкың белән горурлану мотивлары өстәлгән:

Үс тизрәк, үс, күз нурым,
Үскәч белем алырсың.
Кирәк булса халкың өчен
Ил сакларга барырсың.

Татар бишек җырлары арасында автор җырлары – танылган татар шагыйрьләре һәм композиторлары тарафыннан иҗат ителгәннәре күренекле урын алып тора. Г. Тукай (халык көе), Р. Миңнуллин (Р. Абдуллин көе), Дәрдмәнд (Ш. Шәрифуллин һәм Р. Әхиярова көе), Л. Лерон (халык көе), Р. Вәлиева (Ш. Тимербулатов көе) һәм башкалар шигырьләренә язылган бишек җырлары бик популяр. Авторлар иҗат иткән бишек җырлары, халык җырлары кебек, лирик эчтәлек тирәнлеге белән аерылып тора. Ананың баласына булган мәхәббәте иң татлы, назлы сүзләр һәм ягымлы көй белән бирелә. Аларда халык җырларындагы кебек үк эпитетлар һәм чагыштырулардан торган сәнгатьле сурәтләү чаралары, шулай ук, бала тирбәтүнең аерым атмосферасын тудырган «әлли-бәлли», «бәлли-бәү» кебек традицион рефреннар кулланыла.

Алдарак билгеләп үтелгәнчә, бишек җырлары бала табу йолалары кысаларында гына каралмый. Аларның балаларның уен тирәлегендә дә булуы игътибарга лаек. Бу шарт бишек җырларын балалар фольклорына кертеп карарга мөмкинлек бирә – Рәшит Ягъфәров шушы фикердә. Үз фикерен куәтләп, ул «бишек җырлары анадан кыз балага балачагыннан ук күчә» дип билгеләп үтә. Кыз балалар «әниле-бәбиле», «өйле» уйнап, курчакларына өлкәннәр репертуарыннан алынган бишек җырларын җырлый. Бу традицияләрне саклауның үтемле юлы, чөнки үзләштерү һәм ныгыту табигый ысул белән бара.

Татарларда бишек җырлары өлкәннәр аудиториясендә дә, балалар арасында да күп санлы конкурслар, бишек җырлары башкаруга бәйле чаралар аша актуальләшә һәм популярлаша. Мәдәният учреждениеләре билгеле бер акцияләр һәм проектлар кысаларында халык авыз иҗатының әлеге жанрын үстерүгә саллы өлеш кертә, популярлашуына һәм буыннан буынга күчүенә этәргеч бирә. Бу темага мәгариф учреждениеләре үткәргән чаралар аеруча кыйммәтле. Тематик кичәләр, класс сәгатьләре балаларны үз халкының фольклор мирасы белән таныштырырга мөмкинлек бирә, халык авыз иҗатына мәхәббәт тәрбияли, иҗади сәләтен ача.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, бишек җырлары халык иҗатының бүген дә көнкүрештә кулланыла торган жанрына карый. Аларның актуальлеге бала тәрбияләү процессындагы нәсыйхәт, этнопедагогик, этико-эстетик бурычларга бәйле. Бишек җырлары яңа буынның этник үзаңын формалаштыруда кыйммәтле чыганак булып торган дөньяга караш үзенчәлекләрен, мәдәни кыйммәтләрне, этнографик детальләрне, татар халкының тел байлыгын ача.

Чыганаклар:
1. Ахметьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. I том (А-Л). – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2018. – 406 б.
2. Бакиров М.Х. Татарский фольклор: монография. Второе дополненное издание. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2018. – 406 с.
3. Капица Ф.С. Русский детский фольклор. Учебное пособие для студентов ВУЗов / Ф. Капица, Т. Колядич. – М.: Флинта, 2002. – 315 с.
4. Мартынова А.Н. Русская колыбельная песня и крестьянский быт: автореф. дис… канд. ист. наук; АН СССР. Ин-т этнографии им. Н.Н. Миклухо-Маклая. – Л., 1977. – 18 с.
5. Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры / Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләр әзерләүче Р.Ф. Ягъфәров. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1993. – 336 б.
6. Тукай Г.М. Әсәрләр. Биш томда. Шигырьләр, поэмалар (1909-1913). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. – 399 б.
7. Хафизова Л.Р. Бука как персонаж детского фольклора. Славянский и балканский фольклор. Детская демонология. – М.: Индрик, 2000. – С. 198-211.
8. Ягафаров Р.Ф. Татарский детский фольклор. – Казань: Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2007. – 171 с.

Мөслимә ГАЙНИЕВА,
Минзәлә, Тауасты Байлар авылы Мәдәният йорты,
«Нур» халык театры режиссеры

«Беренче көлтә» бәйрәме

АВЫЛЛАРДА УРАККА ТӨШҮНЕҢ БОРЫНГЫДАН КИЛГӘН ҮЗ ТӘРТИБЕ, ҮЗ ЯМЕ БУЛГАН. ИГЕННӘР ӨЛГЕРГӘЧ, УРАККА ТӨШӘР ВАКЫТ ҖИТКӘЧ, КӨЛТӘ БӘЙРӘМЕ ҮТКӘРЕЛГӘН. ЯШЕ-КАРТЫ, БАЛА-ЧАГАСЫ ӘБӘД ТӨЕНЧЕКЛӘРЕН КҮТӘРЕП ИРТӘ ТАҢНАН ЭШКӘ КУЗГАЛГАН. ИРТӘНГЕ ДҮРТТӘН СОҢГА КАЛГАН КЕШЕЛӘРНЕ БАСУ КАПКАСЫННАН КЕРТМИ ТОРГАН БУЛГАННАР, ДИП ИСКӘ АЛА КАРТЛАР.

Басудагы әбәд үзе бер бәйрәм төсен алган. Кырда ашарга пешерүче «кашавар» дип аталган. Ул умач уып, әбәд вакытында тәмле аш пешергән. Кашавар кояш төш турысына җитүен атламлап билгеләгәч, кырда эшләүче халыкны ашарга чакырган. Халык ашаганда бригадир эш күрсәткечләре белән таныштырган. Алдынгы бригадага Кызыл әләм тапшырылса, артта калган бригадага ташбака төшерелгән чыпта бирелгән. Әлбәттә татар халкы уен көлкегә бик оста булган. Ашаган вакытта да шаярышып алганнар.

Минзәлә районының Тауасты Байлар авылында 2004 елдан бирле «Беренче көлтә» бәйрәме үткәрелеп килә. Борынгы бәйрәмне яңарту өчен без аның турында авылыбызның иң өлкән әби-апаларыннан сораштык. Аларның истәлекләрен, кызыклы фикерләрен тупладык. Гайшә әби Гыйләҗева белән Мөсфирә әби Гайнетдинова иң зур ярдәмчеләребез булды – бәйрәмне аларның хатирәләре буенча үткәрә башладык. Тауасты Байлар Мәдәният йорты каршында эшләп килүче музейга куелган экспонатлар – борынгы милли киемнәр, ураклар, байракларның да кирәге чыкты. Бәйрәм фольклор коллективы белән бергә үткәрелә.

Хәзер бу бәйрәмне халык көтеп ала башлады. Бәйрәмдә киенү өчен сандык төпләреннән әби-бабайлардан калган чабаталар, суккан тастымаллар, борынгы күлмәкләр чыга. Әче камырга көлчә пешерелә, басуга баргач ашар өчен йомырка, сөт, ипи телемнәре белән әбәд төенчеге әзерләнә. Урам башыннан җигелгән атлар килә. «Әйдәгез, уракка төшәр чак җитте», – дигән чакыру яңгырый. Хатын-кызлар төенчекләрен, ургакларын кыстырып, арбага чыгып утыра баралар...

Хәзер бәйрәм бүгенге заманга яраклаштырып үткәрелә – басу-кырларда комбайннар көтеп тора. Беренче көлтәләрне бәйләп, илгә-көнгә иминлек теләп эш башлана. Әлбәттә, җыр, уен, көлке белән бергә эш тә кайный. Әбәд җиткәч, апа-сеңелләр үзләре белән алып килгән калай кружкаларын, алюмин калакларын чыгаралар. Пешкән йомырка, элеккегечә күкрәккә терәп киселгән арыш ипие суккан эскәтерләргә куела, кашавар умач бүлә. Ашъяулык тирәли тезелешеп утырып колхозчылар, комбайнчылар әбәд ашый. Ә без, клуб хезмәткәрләре, музеебызда сакланган 1960 еллардагы журналларны алып килеп, халыкны ул чордагы эш күрсәткечләре белән таныштырабыз, быелгысы белән чагыштырабыз.

Ялкау хатыннар образын кертү дә бәйрәмгә бер күңеллелек өсти.

Узган ел әлеге бәйрәмгә районыбызның Түбән Тәкермән, Тулбай, Исәнгол, Түбән Юшады, Калтак авыллары да кушылды.

Ни өчен үткәрелә соң «Беренче көлтә» бәйрәме? Үзебез белгәнне яшь буынга – балаларыбызга, оныкларыбызга калдыру – безнең бурыч. Халкыбызның тарихын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, җыр-моңнарын, уеннарын, сөйләмен, икмәкнең каян килгәнен, ничек эшләнгәнен алар да белергә тиеш.

Фоторәсемнәр menzela.ru сайтыннан

Розалия ӘХӘТОВА,
Зәй, Куш-Елга авылы китапханәчесе

АШЫТ җыены

ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ МИЛЛӘТНЕ МИЛЛӘТ, ТЕЛНЕ ТЕЛ ИТЕП САКЛАГАН, БУЫННАРДАН БУЫННАРГА КҮЧКӘН БӘЙРӘМНӘРЕ, ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ, ЙОЛАЛАРЫ БАР. ШУЛАР АРАСЫНДА САБАН ТУЕ БЕЛӘН ҖЫЕН ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕЛӘРЕ.

Безнең Зәй районы Куш-Елга авылында җыен урак өстенә туры китереп уздырылган. Җыенга берничә көн кала 3-4 егет, бизәлгән атка атланып, күрше-тирә авылларга хәбәр салып йөргән. Аларны яшь кызлар, яшь киленнәр каршы алып, үзләренә чигелгән сөлге, кулъяулык бүләк иткәннәр. Җыен көнне кыңгыраулы атларга утырып, гармун уйнап, җырлар җырлап, авылга кунаклар килгән.

Куш-Елга авылы (аның тарихи икенче исеме – Ашыт) халкы кунакларны сый-хөрмәт, җырбию, көләч йөз белән каршы алган. Җыен бу авылда атна буена барган, көндезләрен бергәләп урак урганнар, урманчының урманын чистартканнар, нигезләре әзер йорт-мунчаларны өмә белән торгызганнар.

Көндезләрен Куш-Елга авылы халкы кунаклары белән олы хезмәттә булса, кичләрен егет-кызлар, яшь килен-кияүләр матур тау битенә кичке түгәрәк уенга җыелган. Гармун, җыр-моң, такмаклар белән «Алтылы», «Сигезле», «Чылбырлы», «Пар булдыру» уеннарын уйнаганнар. Ак сакаллы бабайларыбыз, ак яулыклы әбиләребез сөйләүләре буенча, җыен кичләрендә кунакка килгән егетләр, кызлар танышып парлы булып, туйлар иткәннәр һәм иң кызыгы, ул вакытларда кыз урлаулар да булган.

Атна буе уздырылган җыенның соңгы көнендә зур казаннар асып, җыен боламыгы, тәмле коймаклар, чәк-чәк, гөлбанак пешерелгән, юкә балы белән мәтрүшкәле чәй эчелгән. Ашыт төбәгендә генә әзерләнә торган эчемлекләр – солы-арпа кесәле белән җиләк-җимештән генә әзерләнгән эче балны татып, бәйрәм итеп, кунаклар таралышкан. Бераз эшен тәмамлагач, авыл халкы күрше авылларга да барып, каз өмәсендә, кич утыруларда, туйларда катнашып, бик дус-тату, бердәм яшәгән.

Ләкин ил өстенә килгән 1921 елгы ачлык, шул ук елны Куш-Елга авылында булган янгын һәм илебез өстенә килгән афәт – Бөек Ватан сугышы җыен бәйрәмен юкка чыгарган, оныттырган.

Еллар артыннан еллар узган. Куш-Елга авылының югалган җыенын торгызу өчен бу авылга, тумышы белән Башкортстан якларыннан булган, Ралия Әхмәдуллинаның гаиләсе күчеп кайтуы кирәк булгандыр, мөгаен. Ралия ханым лаеклы ялда булуына карамастан, авылдагы мәдәният йортына эшкә урнашып, 10 елга якын эшли. Аның 20 еллык педагогик стажы, 19 ел медицина өлкәсендә эшләве, Чаллы шәһәрендә үзешчән

түгәрәкләрдә җыйган тәҗрибәсе халык белән тиз арада уртак тел табарга ярдәм итә.

Менә сигез ел инде Ашыт җыены август аенда олы бәйрәм итеп уздырыла. Элеккедән килгән гореф-гадәт буенча, җыенга 3-4 көн кала, күрше авылларны кунакка чакырабыз. Чит җирләрдә гомер итүче авылдашларыбызга да хәбәр итәбез.

Җыен көнне кунакларны милли киемле яшьләр һәм мәдәният йортында эшләп килгән «Ядегәр» җыр ансамбле каршы алып, мәйданга озатып куя. Бизәлгән кыңгыраулы атлар белән зыялы кунакларыбыз, шәхесләребез мәйданга үтеп, көчле алкышлар астында, түгәрәк әйләнә.

Бәйрәм моңлы азан әйтелгәч, җыен әләме күтәрелгәч башлана. Ел саен әби-бабаларыбызның көнкүреш йолалары – «Ашыт авылы тарихы», «Печән өсте», «Уракка төшү», «Өмә», «Кыз урлау» һәм башкалар сәхнәләштереп, халыкка күрсәтелә. Мәйданга өлкәннәр чакырыла, аларның һәм күренекле шәхесләрнең шәҗәрә агачына, юбилярларга, никах-туйларга, яңа туган сабыйларга, хезмәттә зур казанышлар ирешкәннәргә һәм башка төрле авылыбыз өчен мөһим булган вакыйгаларга мәдхия кылына. Авылдашларыбызның сәләтләре, чакырылган җырчыларның чыгышы, күңелләрне дәртләндереп уйнаган гармун моңына «Алтылы», «Сигезле», «Чылбырлы» түгәрәк уеннары һәм башкалар – җыеныбызның иң матур өлеше була.

Җыеныбызның икенче өлешендә чәй өстәленә, Ашыт җыенында гына пешерелә торган боламыктан (берничә төрле ярмага бераз он кушып пешерелә, һәм каз мае салып болгатыла) авыз итәргә узабыз. Биредә илебезнең төрле почмакларында яшәүче, җыенга кунакка кайткан авылдашлар, сыйныфташлар, кардәш-ыру, авылыбызның Закир Сәлимов исемен йөрткән үзәк урамдагы Закировлар нәселе очраша (аларның саны күптән 100дән арткан). Ашыт җыены мәйданында таңга кадәр гармун моңы, җыр-биюләр, түгәрәк уеннар дәвам итә.

Фоторәсемнәр Розалия Әхәтованың шәхси архивыннан

Евгения ШЕМЕЛОВА,
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге методисты

СМӘЕЛ *осталарының тылсымлы* талчыбыгы

БАЛТАЧ РАЙОНЫНЫҢ СМӘЕЛ АВЫЛЫ ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН ТАЛЧЫБЫК ҮРҮЧЕЛӘР БЕЛӘН ДАН ТОТКАН. СМӘЕЛДӘ БУ ҺӨНӘРНЕҢ КИҢ ТАРАЛУЫНДА ШУШЫ АВЫЛ КЕШЕСЕ МӨХӘММӘТНӘБИ АГА ШӘЯХТӘМОВНЫҢ (1909-1996) ӨЛЕШЕ ЗУР. КАЗАН АРТЫНДА ИҢ ШӘП ТАЛБИШЕКЛӘРНЕ, ӨСТӘЛ-УРЫНДЫКЛАРНЫ, КӘНӘФИЛӘРНЕ, ЙОРТ-ҖИР БИЗӘКЛӘРЕН, КӨНКҮРЕШ КИРӘК-ЯРАКЛАРЫН ҮРҮЧЕ БУЛАРАК УЛ ДАН ТОТКАН. ҮРЕЛГӘН ЙОРТ ҖИҺАЗЛАРЫ ЯСАУЧЫ КАРАДУГАН ФАБРИКАСЫНЫҢ ЧЕПЬЯ АВЫЛЫНДАГЫ ФИЛИАЛЫ ДА АНЫҢ ИНИЦИАТИВАСЫ БЕЛӘН АЧЫЛГАН.

Мөхәммәтнәби аганың кызы Әлфинур Гарифҗанова истәлекләреннән: *«Талчыбыктан әйберләр үрү безнең нәселдә буыннан буынга күчеп килгән һөнәр. Әтинең укырга мөмкинлеге булмаган – үсмерчактан ук колхозда эшли башлаган, ә эштән соң өендә үргән дә үргән. Бөек Ватан сугышы башлангач әти хәрби хезмәткә чакырылган. Әмма буе бәләкәй булганлыктан, фронтка алмаганнар: Мәскәүдә хәрби предприятиедә эшләгән, аннары шахтага киткән.*

Әтием Смәелгә 1960 елда гына кайтып кергән. Авылда ата-бабадан килгән һөнәрен яңартып җибәргән – талчыбыктан әйберләр үрә башлаган. Чыбыкны да үзе әзерләгән: чистарткан, пешекләгән. Ясаган әйберләре чыдам һәм матур килеп чыккан, ул үзенчәлекле итеп толымлап үргән. Әтигә заказлар да бик күп килгән, Татарстаннан гына түгел, бөтен Союздан, хәтта Сахалиннан да соратып алганнар. Аеруча талбишекләргә ихтыяҗ зур булган. Нәкъ шушы талбишекләр өчен ул 1980 елда Мәскәүдә узган Бөтенсоюз күргәзмәсендә


Мөхәммәтнәби ага

Әлфинур Гарифҗанова

1 нче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнгән. Безгә – кызларына да – бирнә үрде: өстәл, урындыклар, кәнәфи. Алар әти турында гаҗәеп хатирәләрне саклый».

Мөхәммәтнәби ага эшләренең бер өлеше киленендә – улының тол хатынында – Минзәлә Шәяхтәмовада саклана. Барысы да карап туйгысыз матур һәм бүген генә ясап куйган кебек – өстенә тузан да кунмаган.

Смәелнең чыбык үрү тарихында Якуповлар династиясе дә зур урын алып тора. Харис ага (1936-2003) белән Мөхәммәтнәби ага күршеләр. Талчыбык үрергә әтисеннән өйрәнсә дә, Харис ага үрү техникасы буенча Мөхәммәтнәби агадан дәресләр алган, алып кына да калмаган, камилләштергән. Әйтик, Мөхәммәтнәби ага толымнар белән урындыкларның, кәнәфи һәм диваннарның аркасын гына бизәсә, Харис ага ясаган җиһазларның ян-яклары да толымлап үрелгән. Аның кулы кагылган һәр җиһаз – чын сәнгать әсәре. Харис ага җиһазлардан тыш, кәрзиннәр, чәчәк савытлары да үргән, аеруча зур ихтыяҗ, әлбәттә, талбишекләргә булган.

Мөхәммәтнәби ага эшләре

Харис Якупов

Харис Якупов эшләре

Ни кызганыч, Мөхәммәтнәби ага гаиләсендә әтисе эшен дәвам итүче юк (улы Хәлим, әтисе кебек, инде гүр иясе). Ә менә Харис аганың улы Рәис Якупов талчыбык үрү һөнәрен ике династия өчен дә дәвам итә. Ул районда талчыбык үрүче осталарның да остасы. Рәис, данлыклы авылдашлары кебек үк, теләсә нәрсә үрә ала. Аның бишекләре һәм артсыз урындыклары республика буенча таралган. Әтисе кебек, өстәл-урындыклар-ны да бик рәхәтләнеп үрер иде, әмма хәзер аларга ихтыяҗ юк.

Смәел районның иң яхшы чыбык үрүчеләр авылы маркасын саклый икән – бу Рәиснең эшенә бәйле.

Рәис Якупов остаханәсендә

Рәис Якупов бишекләре

Смәел авылы зур һәм нык. Биредә 800гә якын кеше яши. Авыл мәдәният йортын-да Смәел осталарына багышланган музей экспозициясе ачарга мөмкинлекләр бар. Шул базада яшьләр һәм балалар өчен осталык дәресләре дә үткәреп булса, Смәелдә талчы-бык үрүчеләрнең яңа буыны үсәр иде.

Фирая Зыятдинова фоторәсемнәре

Филүзә МӘРДАНОВА,
Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге мөдире

КОЛАК СЫМАН *чигү техникасы*

КОЛАК СЫМАН ЧИГҮ ТЕХНИКАСЫ[1] *(«ТАСМАЛАРДАН ЭЛМӘКЛЕ АППЛИКАЦИЯ» / «ТЫРНАК АЛМАЛАУ»)* – ЧӘЧӘК ТАҖЫ КЕБЕК БӨТЕРЕЛГӘН ТУКЫМА КИСӘКЛӘРЕННӘН РЕЛЬЕФЛЫ ЧӘЧӘК КОМПОЗИЦИЯЛӘРЕ БУЛДЫРУНЫ КҮЗДӘ ТОТА ТОРГАН АППЛИКАЦИЯНЕҢ БЕР ТӨРЕ. ӘЛЕГЕ ТЕХНИКА КАЗАН ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ БАШ КИЕМНӘРЕН БИЗӘР ӨЧЕН КУЛЛАНЫЛГАН. КОЛАК СЫМАН ЧИГҮ ТЕХНИКАСЫ УРТА ИДЕЛ ҺӘМ УРАЛ БУЕНДА ЯШӘҮЧЕ БАШКА ХАЛЫКЛАРНЫҢ СӘНГАТЬ ИҖАТЫНДА ОЧРАМЫЙ.

Татарларның көнкүрешендә чигү зур урын алып торган. Бер яктан, ул йорттагы кул эше булып саналса, икенче яктан, аның кайбер төрләре, аерым алганда, алтын җепләр белән чигү, һөнәрчелеккә әверелгән. Күренекле этнограф Н.И. Воробьев фикеренчә, татар хатын-кызларының ябылып яшәү рәвеше, буш вакытларында тегү-чигү белән шөгыльләнүләре – чигүнең кул эше сыйфатында киң таралуына һәм үсешенә китергән[2].

Татар хатын-кызларының кул эшендә тукымаларны аппликацияләү техникасы аеруча киң таралган. Бизәкләре төрле төстәге ефәк тасмалардан бантик, зигзаг яки ромбик рәвешендә ясалган көнкүреш әйберләре – челтәрле җәймәләр, пәрдәләр безнең көннәргә кадәр килеп җиткән[3].

Тасмалы аппликациянең үзенчәлекле бер төре булып колак сыман чигү техникасы санала. Ул XVIII гасырлардан ук хатын-кыз баш киемен бизәүдә кулланылган[4]. Әлеге техниканың асылы – өчпочмак формасындагы ефәк кисәкләрен җыеп, астра, георгин, хризантемаларга охшаш эре-эре чәчәк композицияләре төзү[5].

Моның өчен чигеләсе өслек тарттырылган тукымага ябыштырыла. Аңа бизәк төшерелә, төсе туры килгән тасмалар (атлас, ефәк, күн, органза) сайлана. Тасмалар зур булмаган буй-буй кисәкләргә, күн кебек сыпылмый торган материал булса, квадратларга бүленә. Бүленгән кисәкләрнең өске ягын, җиңелчә генә артка бөкләп, алга таба каплыйлар. Күн квадратларның капма-каршы яклары бөкләнә. Шул рәвешле колак сыман элемент барлыкка килә. Элементларның аскы өлешен җилемгә манып контур буйлап беркетәләр. Аларның очлары чәчәкнең үзәгенә юнәлтелгән булырга тиеш. Чираттагы

[1] Ушковая техника.
[2] Воробьев Н.И. Казанские татары (этнографические исследования материальной культуры дооктябрьского периода). – Казань: Татгосиздат, 1953. – С. 125.
[3] Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. – Казань: Татарское книжное издательство, 1969. – С. 33-34.
[4] Валиев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. – Казань: Татарское книжное издательство, 1984. – С. 21.
[5] Шунда ук.

Калфак. Казан губерниясе. XIX гасырның беренче яртысы. Бәрхет, тасма, бисер, канитель, «колакландырып» бөтерелгән аппликация, бисер белән чигү. Татарстан Республикасының Милли музееннан

Калфак. Казан губерниясе. XIX гасырның беренче яртысы. Бәрхет, тасма, бисер, канитель, «колакландырып» бөтерелгән аппликация, бисер белән чигү. Татарстан Республикасының Милли музееннан

элементлар да бер-бер артлы шул рәвешле ялгана бара. Һәр яңа рәт алдагысын өлешчә каплый. Шул рәвешле кырыйдан башлап, үзәккә таба чәчәкнең барлык таҗлары тутырыла. Чәчәкнең үзәгендә очлар ныгытыла һәм энҗе бөртекләре, сәйләннәр белән каплана. Шулай итеп, тулышып утырган матур зур чәчәк таҗы барлыкка килә[6].

Элегрәк баш киемнәренә Европадан кайтартылган ефәк чәчәк таҗлары тегелә торган булган, соңрак татар осталары үз сәнгать эшләнмәләрен ясап сата башлаган. Татар халкының мәдәниятен һәм көнкүрешен беренчеләрдән булып өйрәнгән К.Ф. Фукс XIX гасырның беренче яртысында ук калфакларның төсле ефәк буфмуслиннан ясалган чәчәкләр белән бизәлүе турында хәбәр итә[7]. Калфакларны бизәүдә колак сыман чигү техникасы XIX гасыр уртасында киң таралыш ала.

Колак сыман чигү техникасын куллану нәтиҗәсендә баш киеме аеруча да купшы килеп чыккан. Төсле сәйләннәр һәм вак энҗеләрдән төрле ботаклар, бөреләр, бөдрәләр, мыекчалар ясалган. Болар барысы да калфакны декоратив-гамәли сәнгать әсәренә әверелдергән. Авыр, зур калфакның һәр ярусында үзенчәлекле чәчәк композициясе урнашкан, бәрхет буйларны тоташтырган урыннар лиххак чылбырлары – пружиналап бөтерелгән металл җеп астына яшерелгән[8]. Әлеге стилистикада бизәлгән калфаклар татар ханымнары һәм туташлары арасында 1870 елларга кадәр популяр булган.

[6] Сергеева Н.Г. Гомер агачы – Дерево жизни. – Казань: Магариф, 2008. – С. 26-27.
[7] Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань: Тип. Казанск. ун-та, 1884. – 131 с.
[8] Томина Т.А. Традиции отделки татарского народного костюма в современной одежде // Университетский комплекс как региональный центр образования, науки и культуры. Материалы Всероссийской научно-методической конференции. – Оренбург: Оренбургский государственный университет, 2016. – С. 680.

Калфак

Брошь

XIX гасыр ахырына баш киемнәрен бизәү өчен колак сыман чигү техникасы бөтенләй кулланылмый башлый[9]. Беренчедән, әлеге ысул күп хезмәт таләп итә торган эш саналган, икенчедән, бу техника өчен аеруча кыйммәтле нәзек һәм җиңел тукымалар таләп ителгән. Бу үз чиратында баш киеме бәясенең артуына китергән[10].

XX гасыр ахырында колак сыман чигү техникасын реконструкцияләү омтылышлары ясалган. Казан рәссамнары Н. Кузьминых һәм И. Макарова диван мендәрләре ясап, аларны атлас тасмалардан ясалган чәчәкләр белән бизәгәннәр. Әлеге мендәрләр 1990 елда Россия этнография музеенда уздырылган «Традиция һәм мода» күргәзмәсе өчен махсус ясалган[11].

Хәзерге вакытта онытылган колак сыман чигү техникасын торгызу һәм популярлаштыру белән Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасы Әлфия Рәшит кызы Нурхамәтова шөгыльләнә. Андый уникаль техника барлыгын ул 2013 елда Казанда Нурзия Сергеева уздырган осталык дәресендә ишетеп кайта. «Бу техника мине матурлыгы, гадәти булмавы, шул ук вакытта катлаулылыгы белән әсир итте, – дип искә ала оста. Башта «колаклар»ны атлас тасмалардан җыя идем, хәзер капрон тасмалардан ясыйм. Тасма никадәр нәзегрәк булса, чәчәк шулкадәр нәфисрәк чыга. Беренче калфак бизәкләрен кәгазьдә эшләп, эскизларын ясый идем, соңрак барысы да турыдан-туры калфакта «туа» башлады. Баш

[9] Воробьев Н.И. Указ. соч. – С. 123.
[10] Томина Т.А. Указ. соч. – С. 680.
[11] Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е – начало 1990-х годов). – Казань: Фән, 1995. – С. 110.

Әлфия Нурхаметова

киемнәрен генә түгел, сумкаларны да шул техника белән бизим, паннолар да ясыйм. Хәзер шушы техника белән бизәлгән туксанга якын калфагым бар. «Казан» җыр һәм бию ансамбле өчен костюмнар ясаганда чәчәкле-яфраклы бизәкләрне колак сыман чигү техникасы белән ясадым. Тугыз панно чиктем, камзуллар, декоратив мендәрләр һәм брошкалар ясадым».

Ә.Р. Нурхаметованың колак сыман чигеп ясалган калфаклары 2017 елда «Татарстан Республикасының иң яхшы этнографик сувенирлары» дип танылды. 2019 елда аның «Колак сыман чигү техникасын торгызу» проек-

Калфак һәм хатын-кыз сумкасы

Хатын-кызлар сумкасы. Бәрхет, тасма, бисер, стеклярус, «колакландырып» бөтерелгән аппликация

Калфаклар

ТАССРның 100 еллыгына панно

ты «Музей-күргәзмә эшчәнлеге һәм халык һөнәрчелеге» номинациясендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы грантына ия булды. 2020 елда Ә.Р. Нурхаматова «Алтын хәситә» халыкара бәйгесендә катнашты. Ул иҗат иткән әйберләр Мәскәү һәм Татарстан шәһәрләрендә күргәзмәләргә куелды. Алар Төркиядә, Үзбәкстанда һәм Башкортстанда шәхси тупланмаларда саклана.

Хәзерге вакытта Ә.Р. Нурхамәтова җитәкчелек иткән Аксубай туган якны өйрәнү музеенда колак сыман чигү техникасы белән калфаклар һәм сувенирлар әзерләү остаханәсе булдыру планлаштырыла. Музейда яшь буынны милли мираска якынайту максатыннан осталык дәресләре уздырыла.

Фоторәсемнәр Әлфия Нурхамәтованың шәхси архивыннан

Чыганаклар:

1. Валиев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. – Казань: Татарское книжное издательство, 1984. – 188 с.
2. Валеев Ф.Х. Орнамент казанских татар. – Казань: Татарское книжное издательство, 1969. – 202 с.
3. Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е – начало 1990-х годов). – Казань: Фэн, 1995. – 190 с.
4. Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 104 с.
5. Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.У. Декоративно-прикладное искусство казанских татар. – М.: Советский художник, 1990. – 213 с.
6. Воробьев Н.И. Казанские татары (этнографические исследования материальной культуры дооктябрьского периода). – Казань: Татгосиздат, 1953. – 383 с.
7. Гулова Ф.Ф. Татарская народная вышивка. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 80 с.
8. Муртазина С.А., Халимова Р.Р. Исторические мотивы в декоративном решении современных костюмов с применением полимерных материалов // Вестник Казанского технологического университета. – 2014. – № 20. – Т. 17. – С. 151-152.
9. Сергеева Н.Г. Гомер агачы – Дерево жизни. – Казань: Магариф, 2008. – 79 с.
10. Сергеева Н.Г. Татар чигүе – Татарская вышивка. – Казань: Магариф, 2005. – 47 с.
11. Томина Т.А. Традиции отделки татарского народного костюма в современной одежде // Университетский комплекс как региональный центр образования, науки и культуры. Материалы Всероссийской научно-методической конференции. – Оренбург: Оренбургский государственный университет, 2016. – С. 677-681.
12. Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. – Казань: Тип. Казанск. ун-та, 1884. – 131 с.

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,
филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты баш гыйльми хезмәткәре

Сөмбел чәчле татар Ләйләсе

(«Ләйлә-Мәҗнүн» дастанының татар версиясенә мөнәсәбәттә)



Илдар Зарипов рәсеме

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты татарлар яши торган төрле төбәкләргә оештыра торган фәнни экспедицияләр вакытында табылган, телдән язып алынган һәм кулъязма фольклор ядкярләре арасында «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанының күп булуы игътибарны җәлеп итә. Шунысы кызык: әлеге сюжет халыкка Татарстан районнарында да, Россиянең татарлар күпләп яши торган Идел-Урал регионында да, Себердә һәм башка территорияләрдә дә бердәй таныш. «Ләйлә-Мәҗнүн»не борынгылардан ишетеп беләбез дигән саран гына мәгълүмат бирүчеләрдән алып, әсәрнең эчтәлеген хәтерләүче милләттәшләребезнең һәм хәтта дастаннан эпик җырны көйләп әйтеп бирүчеләрнең, бу дастанның гарәп язулы кулъязма текстларын саклаучыларның әле бүгенгәчә очравы сюжетның татарларда тирән тамырлы булуын искәртә. Татарлар яшәгән урыннарда очрап торган сөйләмә вариантлар яисә гарәп язулы, татар телле язма текстлар, фактик материал буларак, татарларда «Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетлы дастанның башка халыклардан аермалы үз версиясе булуын дәлилли.

«Ләйлә белән Мәҗнүн»нең татар версиясе Низами Ганҗәви, Физули, Нәвои, Җами әсәрләренең, башка язма чыганакларның турыдан-туры яисә ирекле тәрҗемәләре түгел, ә берничә вариантта таралган, Идел-Урал җирлегендә барлыкка килгән мөстәкыйль әсәрләр булуы белән әһәмиятле. Болар – нигездә чәчмә характердагы, чагыштырмача гади сюжетлы, күләме артык зур булмаган дастаннар. Татар версиясенең иң камил вариантлары – безнең көннәргә язмада килеп җиткәннәре.

Татар фольклорында эпос-дастанның китаби төре өстенлек алган булу «Ләйлә-Мәҗнүн» сюжетына корылган истәлекләрдә чагылмый калмаган.

«Ләйлә белән Мәҗнүн» сюжетына милли вариантларыбызның барысына да хас бер сыйфат – алар соңгырак чор татар тормышына яраклаштырылганнар, шул чор татар менталитеты белән сугарылганнар. Сюжеты кыска һәм гади, төп каһарманнары тыйнак һәм сабыр. Текстлар геройларның эмоциональ хәле-халәте өчен укучыны яисә тыңлаучыны борчылырга мәҗбүр итә торган итеп корылган. Дастанның трагизм белән сугарылган булуының нигезендә әнә шул мотив ята.

Дастанның кульъязмалар булып таралган нөсхәләренә килсәк, «Ләйлә белән Мәҗнүн»нең кульъязма текстларыннан иң күләмлесе – татар журналисты Борһан Шәрәф (1883-1943) китаплары арасыннан галимә Флора Әхмәтова тапкан вариант. Ул 32 битне тәшкил итә. Язылу вакыты, урыны, күчерүче-авторы күрсәтелмәгән. Әсәр Бакый ага Урманче тарафыннан хәзерге язуга күчерелеп, «Татар халык иҗаты» җыентыгында урын алган. Шартлы рәвештә Борһан Шәрәф варианты дип аталган, Б. Урманченың да талантлы кулы аша үткән әлеге әсәр мисалында дастанда Ләйлә образының көнчыгыш әсәрләрендәгедән ни дәрәҗәдә үзгә булуын барлыйк.

Эчтәлеге белән дастан Низами Ганҗәвинең (Низами Гянджеви) атаклы әсәренә охшаш, әмма аермалар шактый. Дастанның һәр детале халыкчанлыкка, фольклор традицияләренә үтә якын.

«Ләйләнең мәктәбе башланып, Кайсның гашыйк улдыкыдыр» дигән бүлектә укучы-тыңлаучы Ләйлә белән таныша. Ләйләнең гүзәллеген тасвирлауда Борынгы Көнчыгыш әдәбияты традицияләре киң файдаланылган. Аның рөхләре (йөзе) – гөл, саче – сөмбел, бәге гамбәр (чәче хуш исле), кашы камәр (айдай), гамзәсе (керфек кагуы) хәнҗәр, күзләре мәзмүр, ягъни сөрмәле, көмеш тәне, бәдәне бер маһитаптыр (ай нуры). Татар дастанында чәчмә юллар белән тасвирланган бу гүзәллекне Низами Ганҗәви сынландыруында карасак, карала торган дастан белән әдәби поэма арасында охшашлык та, зур аерма да булуын күрәбез:

«В кудрях полночных лик ее сиял,
Казалось – ворон в когти светоч взял.
Медвяный ротик, сладость скрыта
в нем,
Был чуть приметным оттенен
пушком».
(Низами Гянджеви)

Игътибар итсәк, татар кульъязмасында сурәтләнгән Ләйләнең чәче – сөмбел. Сөнбел – хәзерге татар телендә кулланыла торган фарсы сүзе, «башак, ашлык башагы» яисә гиацинт исемле чәчәк дигән мәгънәсе бар, «сөнбелә» рәвешендә исә август ае һәм шулай ук ашлык башагы дигән мәгънәне белдерә. Ефәктәй тере, алтындай ялтырап торган кызлар чәчен сөмбел белән чагыштыру – төрки халыклар фольклоры һәм әдәбияты өчен традицион сурәтләү чарасы. Татарларда аксыл чәчле кыз балаларны сөмбеләгә тиңләү, аксыл йөзле балага Сөмбелә, Сөмбел исемнәре кушу гадәте әле хәзер дә бар. Татар кульъязмасында тасвирланган Ләйләнең дә чәче сөмбел белән чагыштырылган. Димәк, татар Ләйләсе кара түгел, ә ак тәнле, саргылт чәчле чибәркәй итеп күзаллана.

Ә Низами Ләйләсенең исеме җисеменә тәңгәл (Ләйлә – төн, караңгы төн дигән сүз). Төн – караңгылык символы, димәк, чыннан да, кара чәчле кыз балага күбрәк туры килә. Низамида кызның төндәй кара чәч бөдрәләре арасыннан ап-ак йөзе балкып торуы гаҗәеп осталык белән сурәтләнгән: «Казалось – ворон в когти светоч взял». Низами Ләйләсе, шиксез, кара чәчле, кара күзле гүзәл булып чыга.

Борһан Шәрәф текстына кайтсак, биредә дә Кайс белән Ләйлә мәктәптә укыйлар, хәтта бер үк хәлфәдән белем алалар. Кайс, Ләйләнең чибәрлеген күреп, бар дөньясын оныта. Ләйлә дә Кайска үлеп гашыйк була. Гашыйкларның бер-берсенә мөнәсәбәтен күреп, «Бу нинди ярамас эш?» – дип, гаепләүчеләргә алар:

«Кил и насих, куй нәсыйхәт, күңелдән бихәбәрсең,

Бәни дивана итте ул, белмәм, нә диярсең сән», – дип җавап бирәләр.

Мәхәббәттән Кайс шулкадәр бәргәләнә, мондый көчле хисне аның психикасы хәтта күтәрә алмый башлый. Ул сахрага китеп, хәленә туры килә торган шигырьләр сөйләп йөри, әкренләп авыруга сабыша. Кайсның атасы, улының дәртле гыйшкыннан хәбәрдар булып, Ләйләне Кайска хатынлыкка бирүне сорап килә. Ләйләнең атасы,«Кызыбыз бик яшь әле», дигән сылтау белән, кызын дивана-дәрвишкә бирүдән баш тарта. Кайс кабиләсе, Ләйләдән өмет өзеп, кайтып китәләр.

Низами варианты, авторның оригиналь әсәре буларак, вакыйга уңаеннан автор тарафыннан бирелгән бәягә, индивидуаль фикергә, персонажларны гәүдәләндерүдә психологик сурәткә һәм башка нечкәлекләргә гаять бай булса, Борһан Шәрәф вариантында исә вакыйгаларны сөйләү никадәр генә эмоциональ булмасын, асылда тасвир нейтраль характер ала. Мәсәлән, кызны сорап килеп тә максатларына ирешә алмаган кабилә өйрәнелә торган текстта сүзсез кире борыла, Кайска: «Ләйләдән гүзәл кыз алырбыз» кебек нәсихәтләр бирәләр. Низамида исә кыз ягының авыру кияү егетеннән баш тарту моментына аерым әһәмият бирелгән. Монда кыз ягы, татар дастанындагы кебек: «Эшеңне үти алмыйм, кичер. Хәтереңез калмасын! Кызын диванага бирде дип телләрдә дастан булудан куркам» кебек сүзләр сөйләп, хәтер саклап тормый. Җавап шактый кискен яңгырый: «Не предлагай нам жемчуг свой больной», ягъни мәхәббәттән авыруга сабышкан Кайсны, Мәҗнүн дип атап, кызның әтисе кире кага.

Дастани эпос героеның кыз ярәшү-кыз алу сюжетына бәйле маҗаралары һәр халыкта актуаль саналып, бик күп башка дастаннарда да чагылыш тапкан. Татар романик дастаннарында очрый торган бу сюжет героик эпостагы кәләш эзләү, батырларча өйләнү сюжетын хәтерләтә. Фольклордагы әлеге сюжет борынгы мифтан үсеп чыккан. «Ләйлә белән Мәҗнүн»дә дә бу сюжет бар һәм ул мәңгелек мәхәббәт темасы белән баетылган, теләгәне белән кавыша алмау, сөйгәненнән аерылу мотивлары аша бирелгән.

Чынлыкта әсәрдә конфликтның ничек чишелүе бу очракта әллә ни роль уйнамый. Аның каравы, гашыйклар үлгәч, «Мәҗнүннең якыннары сөякләрен Ләйләнең мәзаре янына дәфен итеп (җирләп), ике гашыйкны бер йиргә китерделәр. Вә болар инде чын кавышуга ирештеләр». Ләйлә белән Мәҗнүннең чын кавышуы башка дөньяда – ислам мифологиясе яссылыгында карасак, Ахирәттә, ә мәҗүси мифологиядән аңлашылганча, Җир асты патшалыгында тормышка аша. Көнчыгышның күпләгән эпик язма истәлекләрендә мифологик теге дөнья һәм бу дөнья сюжеты, алар арасындагы каршылык, конфликтның фәлсәфи чишелеше татар кулъязма дастанында әнә шул рәвешле чагылыш тапкан.

Татар дастанында Ләйлә, Мәҗнүннең үзе хакында сөйләгән бәетләрен ишетеп, аларга каршы үзе дә сөйли. Әйтик, кешеләр авызыннан Мәҗнүннең үзе хакында җырлаган җырларын ишетеп, Ләйлә аларга каршы җыр белән җавап бирә:

Ярабби, дәртемә мәдәт дәрманымны
кустәр!
Я җанымны ал, я җананымны күстәр!
Ягкуб сыйфатындай күзләрем ачылсын,
Еглатма мине, Йосыф Кәнганыны
күстәр!

Ләйлә җавабының эчтәлегенә игътибар итсәк, биредә Ләйлә-Мәҗнүн сюжетына бөтенләй чит сюжет элементлары килеп кергәнен күрәбез. Татар укучысы «Ләйлә белән Мәҗнүн» кулъязмасына кадәр «Йосыф кыйссасы» белән күп элек таныш булган. Ләйләнең, үзенең халәтенә туры китереп, Йосыф вакыйгасын исенә төшерүе дә шуны дәлилли. Йосыф белән бәйле сюжет татарларга Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы аша яхшы таныш, шушы ук сюжет соңыннан халыкта әллә ничә вариантта кулъязмалар булып та таралган, «Йосыф китабы» исеме белән кулдан кулга күчеп укылган, көйләп сөйләнгән. «Ләйлә белән Мәҗнүн» дастанында Ләйлә әйткән җырда телдән телгә күчеп сөйләнә торган шушы дастанның персонажлары искә алынган. Эчке кичерешләрен бераүгә дә сөйләмичә, сөйгәне хәсрәтеннән гел кайгыда йөргән Ләйлә Аллаһыга ялвара, яшерен генә юлга багып, сөйгәне белән кавыштыруны сорый һәм бәет әйтә. Татар кулъязмасында мәңгелек мәхәббәт темасы барлык тулылыгы белән ачылган. Бу – Урта гасыр Көнчыгыш һәм татар әдәбиятыннан килә торган тема.

Дастан укучыны Мәҗнүннең һәм Ләйләнең мәхәббәттән ничек тилмерүләрен тасвирлап мавыктыра, аларны кызгандыра. Эмоциональ-экспрессив тәэсиргә ирешү максатыннан Мәҗнүннең суфиларча гашыйклыгы, сөйгәне белән кавышуга ирешә алмаудан газаплануы тасвирлана, әмма Мәҗнүн һичничек тәнкыйть ителми. Шул ук вакытта дастанда Мәҗнүнне авыруга сабышу халәтеннән чыгарырга тырышучы образлар да бар: улы өчен бик нык кайгырып, малын-мөлкәтен калдырып кешесен шушы хәлдән чыгарырга омтылып йөрүче атасы; Ләйлә белән Мәҗнүнне кавыштырырга теләп тә, теләгенә ирешә алмаган Нәүфәл; сөйгәненең мәхәббәтеннән елап йөргәнен ишетеп-белеп торучы, аның белән бергә булу теләге белән янучы, әмма атасының бәддогасыннан куркучы, Мәҗнүннән аеручы көчләргә хәленнән килгәнчә каршы торучы Ләйлә; Ләйләгә карата җир кешесенә хас хисләр кичереп, аны яратучы Ибне-Сәлам.

Ләйлә образы аша Мәҗнүн илаһи мәхәббәткә омтыла. Дөньяви фикергә, җир кешесе тормышына өндәүчеләргә каршы Мәҗнүннең җавабы: «Минем җананым, бөтен вөҗүде (барлыгы) белән кальбемә (күңелемә) кереп, аңа хәфтан (кием) кеби улмыштыр...». Мәҗнүн, Ләйлә белән үзенең сурәтен күреп, Ләйлә сурәтен бозып ата. Ник болай эшләвенә аңлатма сорагач, ул әйтә: «Мин җананым илә бер улдым. Арабызда синлек вә минлек китмештер», – ди. Мәҗнүн сөйгәне белән рухи кавышуга омтыла. Ул хәтта үлемгә дә суфиларча карый. Ләйләнең атасының гаскәре белән сугышта Нәүфәл гаскәре җиңелгәч, Мәҗнүн, Ләйлә яши торган җиргә килеп, аның иленә авырлык китерүе өчен гафу сорый. «Һәлак итсәгез дә ризамын, сезнең кылычыгыз миңа әбелхәяттер (тереклек суы)», – дип, Ләйлә капкасы янында үлүне бәхеткә санавын белдерә.

Мәҗнүн – мәхәббәткә суфиларча, илаһи якын килүче, ә Ләйлә җир кешесенә хас реаль мәхәббәт тарафдары. Дастанда аларның берсенә дә кискен бәя бирелми, мәхәббәттә янучы бу ике гашыйкның халәте тәнкыйтьләнми, автор-информант мондый катлаулы мөнәсәбәтләрне нейтраль сурәтләп бирүче позициясендә тора. Көнчыгыш Ләйләсе белән чагыштырганда милли версиядәге Ләйлә – шактый кыю, иркен яшәүче, мәхәббәтенә тугры, үз дигәне өчен көрәшергә әзер, әмма шул ук вакытта баш-баштаклыклар кылуга сак якын килүче кыз бала.

Татар дастанында мәхәббәт хисе илаһи хис булу белән бергә җиргә якынрак характерга да ия. Монда мәхәббәтне ике төрле аңлау бар: Мәҗнүнчә аңлау һәм Мәҗнүннең әлеге халәтенә җир кешесе күзләре белән карап аңлау. Дастан эчтәлегендә мәхәббәткә карата әлеге ике төрле мөнәсәбәт кискен аерыла, әмма хикәяләүче боларның берсенә дә өстенлек бирми, һәр очракта объективлыкны сакларга тырыша, мәхәббәттән газап чигүче ике яшь кешенең бу дөньядагы хәлен тасвирлап, укучыдан аларны кызгандыра.

Шул рәвешчә, Ләйлә образын чагылдыруы ягыннан әсәр татар җирлегенә якын тора. Ләйлә монда суфичыл образ булудан бигрәк, җир кешесе. Аның мәхәббәте Кайс-Мәҗнүн мәхәббәтеннән үзгә. Ләйлә сөйгән ярына мөнәсәбәттә суфичыл омтылышлардан күпкә азат. Әсәр күпчелеккә йөз тотып, халык кызыксынуын, зәвыгын бик нык истә тотып эшләнгән. Низами поэмасы белән шактый зур сюжет охшашлыгы, хәтта әсәрнең структур корылышы татар телле әлеге кульъязманың әдәби чараларны, алымнарны, формаларны актив үзләштергән булуын күрсәтә, әмма образларда, холык-фигыль ачылышында җирле үзгәрешләр сизелү дастан вариантын үзенчәлекле итә.

Чыганаклар:
1. Татар халык иҗаты. Дастаннар. – Казан: Татар. китап. нәшр., 1984. – 382 б.
2. Низами Гянджеви. Собрание сочинений в пяти томах. Т.3. перевод с фарси Татьяны Стрешневой. – М.: Худ. литер., 1986. – 366 с.
3. Арабско-татарско-русский словарь заимствований. (Арабизмы и фарсизмы в языке татарской литературы). Т. 2. – Казань: Изд-во «Иман», 1993. – 855 с.
4. Арабско-татарско-русский словарь заимствований. (Арабизмы и фарсизмы в языке татарской литературы). Т. 1. – Казань: Изд-во «Иман», 1993. – 448 с.
5. Урманче Ф. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. 3 томда. Т. 2. (Д–С). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 343 б.

Әңгәмәдәш –
Фәния ЛОТФУЛЛИНА

#ҺӘР ЗАМАННЫҢ ҮЗ КӨЕ

«ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ – ХАЛКЫБЫЗ КҮҢЕЛЕНЕҢ ҺИЧ ТӘ ТУТЫКМАС ВӘ КҮГӘРМӘС САФ ВӘ РАУШАН КӨЗГЕСЕДЕР. БУ БЕРТӨРЛЕ СИХЕРЛЕ КӨЗГЕДЕР. ЧӨНКИ ХАЛЫКНЫҢ БЕР ГЕНӘ ҖЫРУЫН ТОТЫП НЕЧКӘЛӘСӘҢ, ШӨБҺӘСЕЗ, АНЫҢ ХАЛӘТЕ РУХИЯСЕН, НӘРСӘ УЙЛАГАНЫН, ВӘ НИ ХАКЫНДА НИНДИ ФИКЕРДӘ ИКӘНЕН БЕЛЕП БУЛАДЫР», – ДИП ЯЗГАН БӨЕК ШАГЫЙРЕБЕЗ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ. ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ ГАСЫРЛАР АША БУЫННАН БУЫНГА САКЛАНЫП КИЛГӘН, АТА-БАБАЛАРЫБЫЗ ТАРАФЫННАН КАЛДЫРЫЛГАН ИҢ КАДЕРЛЕ МИРАСТЫР. ӘММА МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ АСЫЛТАШЫ БУЛЫРДАЙ КҮПМЕ ҖЫР ГАСЫР ТУЗАНЫНА КҮМЕЛЕП ЯТА ТҮГЕЛМЕ? ШУЛ ҖЫРЛАРНЫ ЭЗЛӘП ТАБЫП, ТУПЛАП ТАМАШАЧЫ ХОЗУРЫНА ТАПШЫРУЧЫЛАРНЫҢ ХЕЗМӘТЕ БӘЯЛӘП БЕТЕРГЕСЕЗ. ШУНДЫЙ МИЛЛИ ҖАНЛЫ ЯШЬЛӘРЕБЕЗНЕҢ БЕРСЕ – «РИВАЯТЬ» ТӨРКИ ЭТНИКА ҺӘМ ҺӨНӘРЧЕЛЕК АНСАМБЛЕНЕҢ СӘНГАТЬ ҖИТӘКЧЕСЕ **РУСЛАН ГАБИТОВ** БЕЛӘН ӘҢГӘМӘБЕЗ ШУЛ ТИРӘДӘРӘК БАРЫР.

Руслан Габитов тумышы белән Актаныштан. Алабуга дәүләт педагогика институтын тәмамлаган. Инде 14 ел фольклор юнәлешендә эшли. «Казанда яшәргә дигән хыялым бар иде. Аллага шөкер, шушы хыялым тормышка ашты», – ди ул.

– «Риваять» ансамбле моннан нәкъ ун ел элек – 2011 елда оешты. Баштарак «фольклор ансамбле» дип кенә атала идек, соңрак юнәлешебез бераз үзгәрде: фольклор нигезендә, төрле уен кораллары ярдәмендә заманча музыка үрнәкләре дә тудыра башладык. Беренче елларда ук репертуар туплап, үзебезне төрле конкурсларда сынап карадык. «Татар моңы» конкурсында катнашып, I урынга лаек булдык. Барысы да менә шуннан башланып китте дә инде – үз-үзебезгә ышанычыбыз артты. Пандемиягә кадәр Индонезиягә барып, Халык көннәрендә катнашырга насыйп булды. Ансамблебез белән «Әлиф» спектаклендә уйнадык. Бу спектакль белән Мексикага да барып кайттык. Күптән түгел Румыниядә Рус мәдәнияте көннәрендә катнаштык.

– Хәзерге вакытта ансамбльдә кемнәр эшли?

– Бүгенге көндә без барлыгы 12 кеше. Барысы да югары белемле профессионаллар. Һәрберсе үз эшенең остасы: биючеләребез дә, вокалистлар да, төрле уен коралларында уйнаучы музыкантларыбыз да бар. Ике состав белән эшлибез. Шушы коллектив белән без фольклор музыкасын да уйныйбыз һәм борынгы уен коралларын

пропагандалау юнәлешендә дә эш алып барабыз.

Безнең коллектив өчен ансамбль – яшәү рәвеше! Чөнки эшең чынлап торып нәтиҗәле булсын дисәң, аның белән яшәргә кирәк. Йокларга ятканда да уйлыйсың, шуның белән уянасың да – шул вакытта гына нәтиҗәсе була. Материал эзлисең, нәрсә күрәсең, нәрсә ишетәсең – шуны язып аласың, анализ ясыйсың. Гади генә тоелган халык музыкасын алып та, фантазия кушып эшләгәндә, бик кызыклы композицияләр ясарга була. Бездә попуррилар күп, шулай ук яңа көйләребез дә байтак.

Тагын бер максатыбыз – төрле уен коралларын барлау, борынгы тарихи уен коралларын реконструкцияләү, аларны пропагандалау, торгызу юнәлешендә эш алып бару.

– Шундый берничә милли уен кораллары турында сөйләп китегез әле.

– Безнең татар халкында үзле балчыктан ясалган уен коралын Европада «окарина» дип йөртәләр. Ул тынлы уен коралы. Күбрәк үрдәк формасында, каз формасындагылары да була. Уелмалары төрлечә булырга мөмкин, 3-4 яисә 7 гә кадәр. Ул күбрәк бишек җырлары өчен кулай.

Тынлы уен коралларыннан, курай турында аерым сөйләп үтәсем килә. Татарларда берничә төрле курай бар. Мәсәлән, **кыска курай**. Ә озын курайны **кырлы курай** дибез, хәзер аны **башкорт курае** буларак та беләләр. Аның сыбызгы өлеше юк. Күп кеше металлдан ясалган курайда уйный – чөнки аның тавышы яңгырап тора, ерактан ук ишетелә. Ә минем күңелемә агач курай якын – студиядә яздырганда, агач курайның тембры ошый.

Нугай курае безнең халыкның тарихы белән тыгыз бәйле. Курайның бер башында сыбызгы өлеше була, элеккеге вакытта сыбызгы ясамаганнар, ә тел ярдәмендә уйнаганнар. Аны болыннарда, су буйларында үсеп утыра торган төрле корыган үләннәрдән ясыйлар. Шуңа күрә бу уен коралының икенче атамасы – **тел курае**. Тавыш югарылыгы ике уем ярдәмендә көйләнә. Бу уен пентатоникага корылган. **Камыш сорнай** камыштан яки камылдан ясала. Безнең Кабан күле буенда 2 метрлы камышлар үсеп утыра. Аларны җыеп шушы уен коралын ясарга мөмкин. Безнең Татарстанда мондый үләннәр сирәк үсә, әмма бар. Украинда бу уен коралы «пищик» дип атала. Кечкенә генә, юка гына булса да тавышы көчле.

Шулай ук **классик сорнай** бар. Кемдер аны фольклор уен коралларына кертү дөрес түгел ди. Чөнки монда металл, пластик элементлар бар. Элек аны агачтан яки мөгездән ясаганнар. **Кубыз** да бик борынгы уен коралы. Мин таныштырган коралларның инде күбесе тарих битләрендә, халык хәтерендә генә калды. Без, «Риваять» этнотөркеме белән, аларны торгызу һәм пропагандалау юнәлешендә эшлибез.

– Руслан, сезне тыңлап утырам да гаҗәпләнеп куям. Ничек барысына да өйрәнеп беттегез? Ялгышмасам, сез бит әле белемегез буенча башка һөнәр иясе.

– Әйе, мин биология укытучысы. Институтны тәмамлауга мәдәни агарту училищесының театраль режиссер бүлегенә укырга кердем. Анда укыганыма бик шатмын, чөнки миндә сөйләм деффектлары, сакаулык бар иде. Аларны төзәттеләр, шигырьне тоемларга, әсәрләрне дөрес сөйләргә өйрәттеләр. Бәлки шуңадыр да бүгенге көндә эшем радио, телевидение белән дә бәйле. Яңа гасыр каналында «Моң сандыгы» сәхифәсен, «Тәртип» радиосында «Риваять» тапшыруын алып барам. Мин анда төрле риваятьләр, мифологик хикәятләр, легендалар сөйлим. Ә инде җырларга һәм төрле музыка коралларында уйнарга «Сорнай» ансамблендә өйрәндем.

– Тагын уен коралларына кайтып, думбра турында да сөйләшеп алыйк әле. Сез аны чит илләргә дә алып чыгасыз, ул юлда авырлык тудырмыймы?

– Кайвакыт таможня хезмәткәрләре белән аңлашылмаучанлык килеп чыга. Үзе җиңел уен коралы булса да, бик озын

ул. Шуңа без хәзер кыска уен кораллары ясатырга бирдек.

Думбра турында бик озаклап, рәхәтләнеп сөйләргә була. Ул безнең төрки халыкларның төп милли уен коралы. Аны төрлечә атыйлар, әмма уйнау принциплары бертөрле. Мәсәлән, бездә – татарда, башкортта, казахта, ногайларда «думбыра» дип аталса, кыргызларда шуңа охшаган уен коралы – «комуз», төрекмәннәрдә һәм үзбәкләрдә «дутар» дип атала. «Ту» (ду) икенче төрле «кыл» дигәнне аңлата, ул фарсыдан кергән. Мәсәлән, чувашларда – «тампра». Башка күчмә халыкларның, мәсәлән, якутларда да шундый ук уен кораллары бар. Думбраны татарныкы түгел, диләр. Нишләп бөтен халык уйнаганда татар гына уйнамасын?! Ул безнең халык авыз иҗатында да сакланган. Думбра турында табышмаклар да, хикәятләр дә, әйтемнәр дә бар. Бервакыт Башкортстанга фестивальгә бардык. Үзебез белән казах думбрасын алып килгән идек. Шунда килгән казахлар безгә карадылар да: «Ә нишләп сез казах думбрасында уйныйсыз. Татарларның үзләренең думбрасы юкмыни?», – диделәр. Миңа уңайсыз булды шул вакытта. Бу вакыйга күңелдә калды. Бер ел эчендә осталар табып, думбраны эшләттем. Хәзер без берничә вариант думбрада уйныйбыз. Думбраны да «татарныкы» дип әйтергә була, чөнки аның үз тамгасы бар. Ул лалә чәчәге белән бизәлгән, элеп куярга уңайлы, үзенчәлекле элмәге дә бар.

– Руслан, бик күп уен кораллары турында сөйләп үттегез. Менә шундый бер җитди сорау бирим әле. Милли уен кораллары турында яшь буын белми, ул мәктәп программаларына кертелмәгән диярлек.

– Әлбәттә, бу бик җитди проблема. Кызганыч, халкыбызның күп милли уен кораллары югалып бара. Шуларның берсе – күптән кулланылыштан төшеп калган думбра. Аны торгызу юнәлешендә эшләргә кирәк. Күпмедер дәрәҗәдә энтузиастлар ярдәмендә эш бара. Әмма дәүләт ярдәме, программалар, конкурс-фестивальләр булмаса, энтузиазм белән генә саклап калып булмый. Мәсәлән, Башкортстан ничек эшләде? Алар һәрбер музыка мәктәбенә курай уйнауны керттеләр, әгәр укучылар курайда уйнамаса, мәктәп аттестация уза алмаячак. Кирәкме, кирәк түгелме – уйныйлар. Шулар арасында барыбер берничә әйбәт музыкант та килеп чыгачак. Ә нишләп безгә дә шулай эшләмәскә?!

Фоторәсемнәр Руслан Габитовның шәхси архивыннан

ХАЛЫК ЗИРӘКЛЕГЕ
әкиятләрдә чагыла

Татар халык әкиятләре / (төз.: Л.Ш. Җамалетдинов, Р. Г. Сәлах). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. – 439 б.

Хәтерлисезме, «Кышкы кичнең озынлыгын сизмисез дә,

Әнкәгезнең сөйләгәне әкият берлә», – дип язган Габдулла Тукай «Кышкы кич» шигырендә, «Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән», – дигән «Туган тел» шигырендә.

Кешенең рухи тормышында әкиятләр үзенчәлекле урын били. Бу әсәрләр белән һәркем сабый чакта ук таныша: аларны балага аның теле ачылгач та сөйли башлыйлар.

«Әдәбият энциклопедиясе»ндә әкияткә түбәндәге билгеләмә бирелгән: «Әкият, – ул халык авыз иҗатының төп жанрларыннан берсе булып, уйдырмага таянган, тылсымлы, маҗаралы яисә көнкүреш характерындагы эпик сәнгать әсәре. Әкият дип телдә яши торган сәнгатьле прозаның төрле төрләрен (хайваннар турындагы гыйбрәтле хикәяләр, тылсымлы әкиятләр, маҗаралы повестьлар, сатирик мәзәкләр) атыйлар, шунлыктан аның үзенә генә хас хосусиятләрен билгеләүдә аерымлык килеп чыга». (Краткая литературная энциклопедия. Т. 6. – М., 1971, 880 столб.).

Әкият дигән сүзнең үзенә килсәк, ул гарәпчә хикәят – сөйләп бирү, хикәя сүзенең фонетик яктан үзгәрүе нәтиҗәсендә хасил булган. Алдарак күргәнебезчә, Г. Тукай үзенең шигырьләрендә бу атамаларның икесен дә кулланган. Өлкән яшьтәге кешеләр арасында әкиятне хикәят дип атаучылар әле бүген дә очрый.

Себер татарлары әкияткә йомак диләр. Йомак өю, йомак ишү әкият сөйләүне аңлата. Ә йомак әйтү – табышмак әйтү. Бүгенге көндә бер-берсеннән бик нык аерылып торган бу ике жанрның, әкият белән табышмакның, әнә шулай исемнәре тәңгәл килү аларның кайчандыр бер ноктадан чыккан булуларына ишарә итә. Аларның уртак исеме йомак фольклорның бик борынгы чордагы синкретик хәлен, ягъни жанрларның аерымланмаган, дөресрәге, аерымланып җитмәгән чорын чагылдыра.

Шулай итеп, йомак – әкиятнең беренче, ягъни борынгы гамәли вазифасына мөнәсәбәтле рәвештә барлыкка килгән һәм бүгенгәчә сакланып калган иң борынгы исеме. Мәсәл-мәсәлә, хикәят дигән атамалар исә әкиятнең соңгырак дәвердәге исемнәре. Ә әкият – иң соңгы, яңа исем. Бу сүз басма чыганакларда беренче мәртәбә А. Троянскийның 1833-1835 елларда нәшер ителгән сүзлегендә очрый, һәм аңа «басня, сказка, небыль, небылица, пустошь, вздор» дигән аңлатма бирелгән.

Әкиятләрдә халыкның күпгасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият явызлыкны гаепли, гаделлекне, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, мәрхәмәтле булырга өйрәтә.

Әкиятләр, нигездә, өч төргә бүлеп карала: хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы әкиятләр һәм көнкүреш әкиятләре.

Хайваннар турындагы әкиятләр. Татар халык әкиятләре арасында хайваннар турындагылары бик аз. Язмалар саны буенча исәпләгәндә, алар әкият репертуарының якынча 8 процентын тәшкил итә. Бу әсәрләрнең күләмнәре дә зур түгел. Аларның төп геройлары – кыргый җанварлар, йорт терлекләре һәм җәнлекләре, кошлар һәм башкалар. Халык арасында «Салам-Торхан», «Аю, бабай, Төл-

ке», «Кәтән Иваныч», «Шәрә Бүре», «Торна белән Төлке», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләрендәге сюжетлар аеруча киң таралган.

Тылсымлы әкиятләр. Бу төрдәге әсәрләр, язмалар саны буенча исәплəгәндә, барлык әкиятләрнең 46 процентын тәшкил итә, аларның күләмнәре дә зур.

Тылсымлы әкиятләрнең күбесенә түбәндәге сюжет хас: булачак герой, үсеп җиткәч, ил гизәргә чыгып китә, төрле маҗараларга очрый, патша кызын аждаһа яки диюләрдән коткара, яисә патша йөкләгән авыр бурычларны үти һәм, нәтиҗәдә, әлеге патша кызына өйләнеп, үзе патша булып кала.

Көнкүреш әкиятләре. Көнкүреш әкиятләре башка төрдәге әкиятләрдән реаль чынбарлыкка гаять якын торулары белән аерылалар. Бу әсәрләр социаль яисә мораль-этик конфликтка корылган, һәм аларның күбесе элеккеге авыл тормышын чагылдыра. Бу әкиятләрнең образлары гадәти, әмма алар, әкият законнары буенча, гадәттән тыш хәлләргә куела.

Килеп чыгышы белән көнкүреш әкияте башка төрдәге әкиятләр кебек үк борынгы; әмма ул, чынбарлыкка аеруча якын булганлыктан, тормышка ныграк яраклашкан, тормыш белән бергә үскән, бергә үзгәргән.

Татар халык әкиятләре репертуарында көнкүреш әкиятләре язмалар саны буенча 46 процент тәшкил итә.

Бу төрдәге әкиятләр үзләренең тематикасы ягыннан шактый чуар. Алар арасында зирәк кешеләр, җитез караклар, хыянәтче һәм тугры хатыннар, бай һәм хезмәтчеләр, дин әһелләре, хәтта аңгыра җеннәр турындагы әсәрләр бар.

Татар көнкүреш әкиятләрендә жанр үзенчәлекләре җәһәтеннән дүрт төркем аерымлана: гыйбрәтле әкиятләр, маҗаралы әкиятләр, юмористик әкиятләр, сатирик әкиятләр.

Бүген сезгә гыйбрәтле әкиятләр төркеменә кергән бер әкият тәкъдим итәбез. Ул әкияттә халыкның бик күп буыннары тарафыннан тупланган тормыш тәҗрибәсе, акылы һәм зирәклеге чагыла.

Әкиятләрне өйрәнү тарихыннан. Татар халкы әкиятләргә бай халык. Ләкин бу хәзинә бик соң җыела башлаган. Беренче басма әкиятләрне без Мартиньян Ивановның 1842 елда Казанда чыккан «Татарская хрестоматия» дигән китабында очратабыз. Бу китап дәреслек сыйфатында нәшер ителгән. Шуңа күрә андагы әкиятләрнең (барысы 8 текст) кайда, кайчан һәм кемнән язып алынганлыгы күрсәтелмәгән!

ВАСЫЯТЬ

Борын заманда булган икән, ди, бер карт. Аның булган, ди, өч улы. Үләр алдыннан карт иң элек үзенең олы улын чакырып алып әйткән:

– Син, улым, дигән, хәлеңнән килсә, авыл саен йорт сал, – дигән.

Шуннан соң уртанчы улын чакырып алган:

– Син, улым, – дигән аңа, – гел тәмле генә ашап тор, – дигән.

Карт кече улына әйткән:

– Син, – дигән, – ешрак өйләнергә кара.

Ярар. Карт үлеп китә. Аталары үлгәч, уллары: «Әти әйткән васыятьне ничек кенә итеп үтәрбез икән?» – дип баш ватып йөри башлыйлар.

Олы улы: «Ничек кенә итеп авыл саен йорт салдырырмын икән?» – дип баш вата, уртанчы улы дөньяда нинди тәмле ризык бар, шуны эзләргә дип чыгып китә, ә кече уллары ешрак өйләнү турында хыялланып йөри башлый.

Көннәрдән бер көнне боларга бер карт килеп керә. Исәнлек-саулык сораша, тормышлары белән кызыксына башлый боларның.

– Тормыш шәптән түгел әле, бабай, – ди олы уллары. – Менә әти үлгән вакытта: «Авыл саен йорт салдыр», – дип әйтеп киткән иде, әле әтинең васыятен үти алганым юк, – ди.

Уртанчысы әйтә:

– Миңа әти тәмле аш кына ашап тор, дип әйткән иде, – ди.

Иң кечеләре дә сүзгә катнашып әйтә:

– Әти миңа: «Ешрак өйләнергә кара, улым», – дип әйткән иде. Мин дә әтинең васыятен үтәргә тырышып карыйм да, барып чыкмый, – ди.

Карт боларның сүзләрен тыңлап-тыңлап тора да болай ди:

– Әй, улларым, сез атагызның васыятен ялгыш аңлагансыз икән, ди. Ул сезгә менә болай дип әйткән, ди: «авыл саен йорт сал» дию «авыл саен дус-иш булдыр, дөньяда дуслар булса, яшәве җиңелрәк була» дип әйтүе булган; «тәмле ашлар гына ашап тор» дию «эшләп ашасаң, кара икмәк тә бик тәмле булыр» дип әйтүе аның; «ешрак өйлән» дип әйтүе, «эш артыннан йөреп, хатыныңны сагыныбрак кайтсаң, көн дә өйләнгән кебек булыр» дип әйтүе ул, ди. Атагыз сезне эшләп көн итәргә өндәгән, – ди.

Шулай дип әйтә дә карт чыгып китә. Шуннан соң болар әтиләренең васыятьләрен ул кушканча үти башлыйлар.

Розалия ШӘЙДУЛЛИНА,
Арча, «Үрнәк» балалар бакчасы музыка җитәкчесе

«Кәккүк чәе» бәйрәме

(МӘКТӘПКӘ ХӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕ ӨЧЕН)

(Кәккүк тавышы ишетелә. Әби өйдән чыга. Уйланып, кәккүк тавышын тыңлап, яшь чагын искә төшереп, эскәмиягә барып утыра. Өйдән оныгы Карина да чыга.)

Карина: Әбием, нәрсә турында уйланып утырасың?

Хиндия әби: Кәккүк тавышын ишетәсеңме, кызым? Яшь чагым исемә төшеп китте... Элек, яз җиткәч, беренче тапкыр кәккүк тавышын ишеткәч, апалар, әбиләр, балалар җыелышып, зур табын ясап, чәйләр эчә идек. Җырлый идек, бии идек, төрле уеннар уйный идек. «Кәккүк чәе» бәйрәме оештыра идек...

Карина: Әбием, әнә күке кычкыра, әйдә бүген дә «Кәккүк чәе» бәйрәмен үткәрик! Мин тиз генә күрше апайларны, әбиләрне, иптәшләремне чакырам – бергәләп утырырбыз!

(Карина йөгереп кереп китә, әби дә өйгә кереп, зур җәймә чыгара. Дусларын чакырып килгән Карина әбисенә җәймә җәешә. Күрше апалар, әбиләр күчтәнәчләр белән килә. Алар җәймә тирәли утырыша. Өлкәнрәкләр эскәмиягә утыра.)

Алсу апа: Безнең күптән болай җыелышканыбыз юк.

Илсөя әби: «Кәккүк чәе» бәйрәме инде онытылган.

Рөстәм:

Кояш нурын сипте җир өстенә,
Исте йомшак җылы җилләре.
Кошлар кайта: сагындырган
Туган-үскән җирләре.

Эльвина:

Көннәрен юлда үткәреп,
Куанышып очалар,
Канатларына күтәреп,
Яз китерә ич алар.

(«Кошлар килде» җыры.)

Карина: Әби, безгә бу бәйрәм турында сөйлә әле.

Хиндия әби: «Кәккүк чәе» – татарларның һәм башкортларның язны каршы алу йоласы. Яздан җәйгә күчү үзенчәлекләрен чагылдырган бу бәйрәм гасырлар буена сакланып килгән. Ул табигатьнең кыштан соң терелүен, күчмә кошлар кайтуына шатлануын күрсәткән. «Кәккүк чәе» – бергәләп чәй эчү, төрле уеннар, җыр-бию һәм багулар. Чәй табынына елга ярына яки тау битенә җыелганнар, кайчагында берәр йорт каршындагы болында сыйланганнар. Бәйрәмдә, нигездә, хатын-кызлар, яшьләр, балалар катнашкан. Кайсы хуҗабикә күбрәк кунакчыллык күрсәтсә, шуның гаиләсе өчен ел иминрәк булыр дип саналган. Борынгы бәйрәм күкчәләрне йомшартудан башланып киткән, моның өчен балалар агач тамырларына сөт, катык сипкәннәр, йомырка салганнар, ә агач ботакларына кызыл тасмалар бәйләгәннәр. Әйдәгез, без дә шулай эшлик!

(Агач төбенә сөт сибәләр, йомырка куялар.)

Хиндия әби: Кызыл тасманы бәйләгәндә үзегезнең иң изге теләкләрегезне әйтегез.

(Агач ботакларына тасмалар бәйлиләр.)

Күке кычкыра башлагач, самавырлар, ризыклар алып, күкегә кунакка бара идек. Чишмә янында, яшел чирәмгә җәймә җәеп, өйдән алып килгән тәм-томнар белән самавыр чәе эчәбез, күкене «сыйлыйбыз», балалар җырлый, бии, төрле уеннар уйный.

(«Чума үрдәк, чума каз» уены.)

Хиндия әби: Кызым, самавыр кайнап чыккандыр.

(Зәринә самавырны алырга өйгә кереп китә. Шул вакытта, бер малай курайда уйный башлый. Зәринә шул малай белән «Самавыр» биюе башкара.)

Булат:

Якты яз җиткәч,
Яшел урманнан
Кәккүк тавышы
Яңгырый һаман:
Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!

Сәфинә:

Башка кошлар күк
Ул оя кормый,
Үстерми бала,
Җырлый да җырлый:
Кәккүк! Кәккүк!
Кәккүк! Кәккүк!

Илсөя әби: Без күкене йомыркасын чит кош оясына ташлавы өчен гаеплибез. Чынында исә, күкенең тән температурасы бик түбән, ул аларны җылыта алмый. Чит кош оясында гына йомыркалардан кошчыклар исән-имин чыга ала.

Алсу апа: Күке турында сынамышлар да бик күп. Мәсәлән, «Кәккүк чәе» үткәрелгән кичтә теләгән теләкләр чынга ашкан.

Айсылу апа: Кызлар күке кычкыруына карап, нинди кешегә кияүгә чыгачагын юраган. Күке күп кычкырса, булачак тормыш иптәше – акыллы, аз кычкырса саран булачак, имеш.

Ясмина: Без дә беләбез: күке бака тавышы чыгарып кычкырса, яңгыр булыр.

Эльвина: Күке кычкырса, су җылына.

Айсылу апа: Минем хәтеремдә: чәйләр эчкәндә, әбиләр күке турында риваятьләр, әкиятләр, гыйбрәтле хикәяләр сөйлиләр иде.

Илсөя әби: «Кәккүк»нең бер риваятендә башкорт нәселләренең берсенә дошманнар һөҗүм итүе турында сөйләнә. Кәккүк исемле батыр егет барлык егетләрне җыеп дошманнарга каршы чыга. Аны Карагаш исемле сөйгән яры озатып кала. Ул сугыштан беркем дә исән кайта алмый. Карагашның Кәккүкнең һәлак булуына ышанасы килми. Әти-әнисе аны яратмаган кешегә кияүгә бирергә теләгәч, ул качып китә. Тик аны эләктереп алалар һәм төрмәгә ябалар. Шул вакытта ул: «Кош булып яратканым янына очарга иде!», – дип теләк тели. Кызның теләге шунда ук чынга аша – ул кошка әверелеп, төрмә тәрәзәсе аша очып чыгып китә. Агачтан-агачка кунып, таудан-тауга очып сөйгәнен чакыра: «Кәк-күк! Кәк-күк!». Шуның өчен аңа «Күке» дип исем кушкалар.

Хиндия әби: Балалар, әйдәгез бергәләп «Зәңгәр чәчәк» уенын уйнап алыйк әле.

(«Зәңгәр чәчәк» уенын уйныйлар. Кулга-кул тотынышып, балалар бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала, чигүле мендәр тотып, уртага чыгып баса.)

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

(Түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр.)

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр –
Мендәреңне сал әле.

(Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Уртага чыгып, бииләр, әйләнәләр. Башка балалар кул чабып торалар.)

Хиндия әби: Бии беләсез, уйный беләсез, әйдәгез, табышмаклар да чишеп карагыз.

Гөлдер-гөлдер гөл итекле,
Гөлкәй кызыл читекле. *(Күгәрчен.)*

Айсылу апа:
Җәй такылдый бу чүкеч,
Кыш такылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч? *(Тукран.)*

Алсу апа:
Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, өй ясый. *(Карлыгач.)*

(«Дүдәк» җыры.)

Илсөя әби: Җәй барыбыз өчен уңышлы булсын, бер-беребезгә матур сүзләрне кызганмыйк.

Ислам:
Таза булыйк, матур булыйк,
күркәм булыйк.
Сөйләшкәндә матур сүзләр
генә сөйлик.
Рәнҗемәсен, боекмасын
дисәң күңел,
Изге сүзләр, җылы куллар,
шатлык телик!

Карина:
Зур бәхетләр юлдаш булсын безгә,
Көннәрне шатлык бизәсен.
Сәламәтлек – ярты бәхет, диләр,
Шушы бәхет читләп үтмәсен.

(Татар халык биюен башкаралар.)

Хиндия әби: Бәйрәмебез ахырына якынлаша, балалар. Гаиләләргә иминлек, сәламәтлек һәм бәхет, мул тормыш теләп, агач төбенә ризыклар салыйк, кәккүкләр җыелып ашасын. Еллар тыныч килсен, ризыклар мул булсын!

Сары агачлар

Наилә Яхина сүзләре һәм көе



Урманнарда бар агачлар
Сап-сары күлмәк кигән.
Ул шулай яшел җәйдән соң,
Безгә сары көз килгән.

Кушымта:
Сары-сары агачларга
Кошлар сайрамый кунып.
Аларны бездән еракка
Күзләр җибәргән куып,
Күзләр җибәргән куып.

Озын-озын болытлары,
Яңгыр яудыра көн дә.
Чылана сары агачлар,
Ышыкламый беркем дә.

Кушымта.

ЭЧӘК БӨККӘНЕ

БҮГЕН БЕЗДӘ КУНАКТА – БИЕКТАУ РАЙОНЫНЫҢ МӘДӘНИЯТ БҮЛЕГЕ ҖИТӘКЧЕСЕ, ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЕ ЛИЛИЯ ЗӨФӘР КЫЗЫ БОРҺАНОВА (СИБГАТОВА).

Тумышы белән Казаннан булса да, Лилиянең балачагы Саба районы Сатыш авылында үтә.

– Әнинең әнисе Һаҗирә әби яши иде анда. Каникул саен төп йорттагыларга өстәлеп, барлыгы җиде бала җыела идек. Әби бик укымышлы иде: гарәпчә дә, латинча да, кириллицада да яза белә иде. Ул гомере буе тегүче булып эшләде, бик күп мал-туар, кош-корт асрады, шуңа ризыкка мул яшәде. Безне сыйлап кына тора иде: күп итеп пилмән ясап куя, токмачлы ашы, камыр ризыгы гел өстәлдә булды. Камыр ризыгы булмаганда ипигә каймак сөртеп, өстенә шикәр комы сибеп ашап йөри идек. Әбинең өстәлендә беркайчан да хәлвә өзелмәде. Күрше-тирә балаларын да ашатып чыгара иде.

Әби пешергән кабак, эчәк бөккәннәрен, балан бәлешен әле дә сагынам. Әбидән күрептер инде, әни дә камыр ашларына бик оста. Ул да эчәк бөккәне пешерергә ярата. Мин дә! Бүген журнал укучыларына да эчәк бөккәне пешереп күрсәтәсем килә, – ди Лилия ханым Борһанова.

КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

Камыр өчен:

180 грамм эретелгән ак май,
1 стакан көнбагыш мае,
2 аш кашыгы кибет каймагы,
2 стакан сөт,
2 аш кашыгы шикәр комы,
1 чәй кашыгы тоз,
йомшак камыр килеп чыгарлык он.

Эчлек өчен:

3-4 баш суган,
1 килограмм эчәк,
6-8 бәрәңге,
төменчә борыч, тоз.

Җиде сорау

1 – Татар хатыны пешерә белергә тиешле өч ризык?

– Татар хатыны токмач кисеп аш, пилмән, өчпочмак пешерә белергә тиеш дип уйлыйм.

2 – Татар ир-аты яраткан өч ризык?

– Иремнән чыгып әйтә алам, өчпочмак, кыстыбый, авыл тавыгы белән ромбиклап киселгән токмачлы аш – ирләр яратып ашый торган ризыклар.

3 – Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша, дигән сүз белән килешәсеңме?

– Юк. Күңелеңдә яхшылык, чисталык булмаса, тәмле телеңне, матур сүзләреңне кызганмасаң гына ир-атны үзеңә каратып була. Ул бик зур әйбер ир-ат өчен. Яратмаса, ашатып кына тотып булмый.

4 – Балачак нинди ризыклар белән хәтереңә уелып калды?

– Балачак әби белән әни пешергән эчәк бөккәне һәм эчәк салып кыздырган, төбе кетер-кетер килеп торган бәрәнге.

5 – Гастрольләрдә йөргәндә кайсы якта нинди милли ризыклар белән сыйлыйлар? Моңарчы күз күрмәгән, ят ризык ашаганың булдымы?

– Шулай бервакыт Башкортстан якларына барып чыктык. Безнең төркемдәге музыкантның өенә кунакка кердек. Шунда беренче тапкыр бишбармак ашадым, искиткеч тәмле иде ул, хәзер үзем дә яратып пешерәм.

6 – Көннәрдән бер көнне Лилия Борһанова ресторан ачса, фирменный ризыгың нәрсә булыр иде икән?

– Ресторан ачу – минем яшьлектәге хыялым инде ул. Анда, әлбәттә, гел безнең милли ризыкларыбыз гына булыр иде. Ә исемен «Бәйрәм» дип атар идем. Тәмле ризык ашау – ул үзе бер бәйрәм. Ресторанымда авыл миче дә булыр иде, ул мичтә мин ипи, коймак, эчәк бөккәннәре пешерер идем.

7 – Француз мәкале: хатын-кыз юктан да скандал, салат һәм эшләпә ясый белә, ди. Эшләпә ясый аласыңа ышанам, ә скандал белән салат ясый алыр идеңме? Ул юктан гына ясалган салатның рецепты ничек?

– Скандал ясау – гомумән минем өчен түгел. Ә менә юктан да салат ясый алам. Мәсәлән, суыткычта булган әйберләрдән – скумбрия консервасы өстенә вак итеп суган турыйсың, майонез сөртәсең, аның өстенә пешкән бәрәңге белән йомырка уасың да тагын бер кат майонез сөртеп куясың. Бик тәмле салат килеп чыга. Җәен мин редиска саласы ясарга яратам. Туралган редиска өстенә ваклап йомырка саласың, күп итеп яшел әнис сибәсең һәм майонез белән болгатасың. Түбәндә тоз, борыч, яшел суган өстисең.

1. Алда әйтелгән барлык ингредиентларны кушып, йомшак кына камыр басабыз. Ясагач, целлофан пакетка салып, камырны 30-40 минут суыткычта ял иттерәбез.

2. Эчлек ясыйбыз: вак итеп суган турыйбыз, аны көнбагыш маенда кыздырабыз. Өстенә эчәк салабыз. Әзер булгач, вак итеп туралган бәрәңгегә кушып, тәменчә тоз, борыч салып болгатабыз.

3. Камырны вак кисәкләргә бүләбез. Җәеп, уртасына эчлекне салабыз.

4. Бөккән рәвешенә китереп бөреп куябыз да, майлы табага тезә барабыз.

5. Әзер бөккәннәрне кайнар мичкә куеп, 40-50 минут пешерәбез.

6. Пешеп чыккач, эчәк бөккәннәрен табынга чыгарыр алдыннан бераз тастымал белән каплап тотабыз.

Ашларыгыз тәмле булсын!

Руслан Гаделшин фоторәсемнәре

Шахворд

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы – ферзьнең дөрес йөреш тәртибен кулланып, Рифат Сәлахның «Алма ява» шигыреннән өзек укыгыз.

♛	К	е	җ	г	ә	я	в	Н	и	җ	и	л	ә.	к	а	м,
ө	г	и	р	а	р	а	ә?	к	н	р	е	Н	н	й	е	с
з	л	и	л	ы	м	л	а	а	е	м	и	и	т	д	и	г
д	җ	м	Җ	ы	е	д	г	м	ү	к	С	а	и	н	р	ә.
ә	а	–	ш	б	ә	л	А	к	а	ю,	с	н	е	ә	Җ	р
я	а	у	м	р	у	л	м	д	ө	ы	а	с	л	и	ә	е
в	л	е	м	т	т	я	ә	с	ң	к	а	з	л	л	ң	л
а	к	о	н	ы	ь	р	н	и	к	г	э	ф	к	Б	ә	ә.
й,	ң	ә	н	н	м	а	к	ы	ы	ы	е	ә	ө	б	Ә	б
б	л	б	ө	о	г	ә	ч	н	н	р	м	д	р	й	ү	ә
е	е	д	ң	л	н	н	ы	р	–	л	р	и	т	к	л	н
л	н	б	у	к	и	п	а	ж	ү	ә	т	е	е	ә	й	ы
ә	е	т	ө	м	А	л	и	к	ч	ә	р	г	к	у	й	ә
л	н	з	Ә	л	а	л	ы	ә	д	с	з	л	п	с	р	д
ә	л	ә.	т	м	ф	р	ч	ң	е	ө	ә	ы	и	и	ә…	
ә	г	ы	л	е	а	л	е	ң	к	р	ч	н	т			
р	н	а	р	с	ә	р	л	ә	–	О	е	ң				



Шахвордның җавабы:

Көзге җилдә җиргә алма ява –
Җыр явамы шулай, кем белә?
Никадәр моң белән тулган җирем
Алтын белән дөньям күмелә.
Никадәр моң белән тулган сөю,
Син кайтасың иске көзләргә.
Ә мин чыккан идем, сине сагынып
Алтын алмаларны эзләргә.
Җилфер-җилфер сары күлмәкләрен
Бәдрә чәчләрендә тирбәлә.
Өтерсең лә көзге күбәләкләр –
Очып уйный синең тирәдә...

Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде

Истәлекле даталар
2021

ОКТЯБРЬ

1 октябрь
Тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү өлкәсендәге мактаулы хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Васил Заһит улы Гарифуллинга 60 яшь (1961)

8 октябрь
Татарстанның халык язучысы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель Баян улы Галиевкә 75 яшь (1946)

12 октябрь
Шагыйрь, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Гарифҗан Садыйк улы Мөхәммәтшинга 80 яшь (1941)

13 октябрь
Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөдәррис Зәфәр улы Әгъләмовның (Әгъләметдинов) тууына 75 ел (1946-2006)

18 октябрь
Шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, журналист һәм тәрҗемәче, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Рәис улы Бохараевның тууына 70 ел (1951-2012)

21 октябрь
Режиссёр, педагог, ТАССРның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе Илдус Нәсыйх улы Зиннуровка 75 яшь (1946)

24 октябрь
Композитор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең Дәүләт премиясе лауреаты, Халыкара конкурслар лауреаты София (Сания) Әсгать кызы Гобәйдуллинага 90 яшь (1931)

НОЯБРЬ

1 ноябрь
Татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь, фольклорчы Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзинең (Фәйзуллин) тууына 130 ел (1891-1928)

1 ноябрь
Композитор, фольклорист, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Котдус Мирзасалих улы Хөснуллинга 80 яшь (1941)

8 ноябрь
Әдәбият галиме, педагог, журналист, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре Альберт Гатуф улы Яхинның тууына 90 ел (1931-2010)

10 ноябрь
Композитор, педагог Рәшит Гомәр улы Гобәйдуллинның тууына 90 ел (1931-2000)

11 ноябрь
Язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Леронга (Лемон Лерон улы Леронов) 60 яшь (1961)

17 ноябрь
Язучы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәровка 80 яшь (1941)

25 ноябрь
График, каллиграф, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Рушан Галәветдин улы Шәмсетдиновка 75 яшь (1946)

ДЕКАБРЬ

4 декабрь
Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Г. Тукай, РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты, Ленин ордены кавалеры Сибгат Таҗи улы Хәкимнең (Хәкимов) тууына 110 ел (1911-1986)

4 декабрь
Әдәбият тәнкыйтьчесе, журналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Фәез Мәүлит улы Зөлкарнәйнең (Зөлкарнәев) тууына 70 ел (1951-1997)

7 декабрь
Тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе Фирдәүс Гариф кызы Гарипованың тууына 80 ел (1941-2014)

15 декабрь
Актёр, Татарстан Республикасының халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты Нуриәхмәт Вәлиәхмәт улы Сафинга 75 яшь (1946)

22 декабрь
График, рәссам, китап бизәүче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган рәссамы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Григорий Львович Эйдиновка 75 яшь (1946)

(Татарстан: Истәлекле һәм онытылмас даталар календаре = Календарь знаменательных и памятных дат. 2021 / Татарстан Респ. Милли к-ханәсе; төз. Г.Ш. Җомаголова; мөх-рләр И.Г. Һадиев, А.Р. Габделхакова. – Казан: Милли китап, 2020. – 168 б.)



Кадерле укучыларыбыз!
2022 елның беренче яртыеллыгы
өчен «Түгәрәк уен» альманахына
республикабызның барлык элемтә
бүлекләрендә, яисә «Почта России»
сайты аша (https://podpiska.pochta.ru
Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип
җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

Индексыбыз – ПА 183
Өч айга язылу бәясе – 192 сум 67 тиен
Ярты елга язылу бәясе – 385 сум 34 тиен

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!